# ТАТАРСТАННЫҢ МӘДӘНИ МИРАСЫ




ФОНД «ВОЗРОЖДЕНИЕ»

«ЯҢАРЫШ» ФОНДЫ

RENAISSANCE FOUNDATION

— 2013 —








«Нәтиҗәсен күрүе күңелле».

Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин.













«Без алынган эш – Болгарны җәм Свияжскины торгызу республикабызныҗкҗпмиллләтле халкы кҗҗеленә хуш килә... җбу иҗюгары бәҗа».

Татарстан РеспубликасыныҗБеренче Президенты,
«Яҗарыш» ФондыныҗПопечительләр Советы рәисе М.Ш.Шәймиев.













«Болгар һәм Свияжск – бик зур әһәмияткә ия изге урыннар, аларны торгызу - игелекле миссия».

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов.

# Фонд тарихы 2010-2013









2010 елның февралендә ТР ның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев Указы нигезендә Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды оештырылды. Аның төп миссиясе - Татарстан җирендә яшәүче күпмилләтле халыкның тарихи, мәдәни, рухи традицияләрен саклау һәм үстерү.

Фонд эшчәнлегенең төп бурычы булып республиканың ике тиңсез хәзинәсен, мөселман һәм православие мәдәнияте үзәкләрен: Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгын һәм «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музеен реставрацияләү тора.

Бу борынгы шәһәрләрнең үзенчәлеге заман рухыннан, иманның һәм мәдәниятнең яңаруын тоюдан, бу якларның архитектура тылсымыннан һәм табигать байлыгыннан гыйбарәт.

2012 елның җәендә Болгарны һәм Зөя утравын карап киткән Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның әлеге яңарышка югары бәя бирүе очраклы түгел.

Республика «Яңарыш» фонды эшләү дәверендә башкарылган эшләр күләме шактый зур. Башкарылган торгызу эшләре нәтиҗәсендә тарихи ядкәрләрнең кыяфәте үзгәрде һәм үзгәрүен дәвам итә. Тарихның, мәдәниятнең, уникаль төзелеш сәнгатенең һәм рухиятнең тиңсез истәлекләрен торгызу буенча бурычлар уңышлы үтәлеп килә.

Проект кысаларында Свияжскида (Зөя утравында) 46 объект һәм Болгарда 40 объект реконструкцияләнә һәм төзелә.

2011-2012 елларда утрауда төзүтөзекләндерү һәм реставрация эшләреннән соң 14 объект ачылды. Утраугa газ кертелде, яңа торак йортлар, юллар, күперләр салынды.

Болгарда 10 объект реставрацияләнде, төзелде һәм куллануга тапшырылды.

Республиканың төзелеш мөмкинлекләре мәдәният истәлекләрен төзүгә һәм реконструкцияләүгә кирәк булган барлык югары таләпләргә җавап бирә.







«Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе (генераль директоры А.А.Хөснетдинов) белгечләренең югары һөнәри осталыгы нәтиҗәсендә Болгардагы борынгы объектлар, Зөя утравындагы мәдәният һәм рухият истәлекләре белән яңа объектлар арасында гармония барлыкка килә. Проект-смета документларын әзерләү буенча эшне коллектив бушлай, хәйрия нигезендә башкара.

Болгарда һәм Зөя утравында башкарылучы эшләргә заказ бирүче - «Татарстан Республикасының баш инвестиция-төзелеш идарәсе» (ГИСУ). Идарә исеменнән эшкә идарә җитәкчесе урынбасары А.С.Усманов күзәтчелек итә.

Болгарда һәм Зөя утравында төп реставрация эшләрен «Татар махсус фәнни-реставрация идарәсе» ябык акционерлык җәмгыяте (ТСНРУ) алып бара (генераль директоры Ю.А.Егорушкин). Реставрацияләүчеләр үз эшләрендә иң яңа технологияләр, оригиналь конструктор алымнары һәм иң өметле тикшеренүләрне кулланалар. Төзелешнең һәм реставрацияләүнең нәкъ менә алга киткән технологияләре борынгы Болгардагы тарихи корылмаларны һәм Зөя утравындагы рус төзелеш сәнгате һәм православие дине ядкәрләрен киләчәк буыннар өчен саклап калу мөмкинлеге бирә.


Болгар һәм Свияжск тарихи-архитектура һәм табигать-ландшафт комплексының уникальлеге аларның ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәният һәм табигать мирасы исемлегенә керүне көтүчеләр исәбендә булуы белән расланган.

Болгарда һәм Зөя утравында борынгылык тылсымын, кабатланмас тарихи рухны саклау белән беррәттән бу җирләрдә архитектура һәм техника үсешенең иң яңа казанышлары буенча җиһазландырылган заманча туристлык үзәкләре булдырыла, инфраструктура (причал, коммуникацияләр, кунакханәләр) үсеше буенча эшләр башкарыла. Бүген төзелгән объектлар киләчәк буыннар өчен бай мирас булачак.



# Болгар. Тарихи белешмә











X-XI гасырларда Болгар шәһәре Көнчыгыш Европаның беренче зур феодаль дәүләтләренең берсе булган Идел буе Болгар дәүләтенең – башкаласы, аннан соң, XIII-XIV гасырларда - Алтын Урданың беренче башкаласы, Алтын Урда составындагы Болгар (Җучи) олысы үзәге. Көнчыгыш

Көнчыгыш Европаның стратегия һәм сәүдә ягыннан иң әһәмиятле урыннарының берсендә – Кама һәм Идел кушылган урында урнашу сәбәпле, Болгар, барлыкка килгән вакытыннан ук, Идел буе халыклары тарихында һәм, гомумән, бөтен Көнчыгыш Европа тарихында җитди роль уйнаган.

922 елда бирелдә болгарлар – хәзерге Казан татарларының ата-бабалары – рәсми рәвештә ислам динен кабул иткәннәр. X гасырда Болгарда яңа дәүләтнең символы – акча - тәңкә сугылган. Шәһәр ул заманда ук чит ил кешеләренең игътибарын җәлеп иткән, аның турында гарәп, фарсы елъязмачылары һәм географлары язып калдырган. Язма чыганакларда, башлыча көнчыгыш чыганакларда, Болгар шәһәре бирегә Ибне Фадлан килгәнче үк телгә алынган. Нумизматика материаллары анализы да әлеге мәгълүматка каршы килми.

Болгар Көнчыгыш Европаның Урта Азия белән сәүдә итүендә төп урынны алып торган. Аның аша көнчыгышка әһәмиятле товарлар – төньяк халыкларның һөнәри һәм аучылык эшләнмәләре узган. Рус товарлары да аның аша үткән. Тора-бара Болгарда төрле һөнәрләр үсеш алган. XII гасырда Болгар, үзенең халыкара базар буларак әһәмиятен югалтмыйча, башкала ролен Биләр шәһәренә биргән. Бу хәл монголларга кадәрге чорда, елга юлы - Идел өчен көрәш барышында шәһәрнең берничә кат җимерелүе аркасында да килеп чыккан.

Бу дәвердә Болгарның икътисады, һөнәрчелеге, сәүдә элемтәләре үскән, биләмәләре арткан, шәһәр тирәли яңа фортификация рәте төзелгән. Шәһәрнең ныгытылган өлеше 1236 елга 24 га тәшкил иткән. Бу чорда Болгарның Русь белән бәйләнешләре көчәйгән.

1236 елда Болгар монголлар тарафыннан яулап алынган һәм яндырылган. Шәһәрнең ныгытмалары җир белән тигезләнгән. Шәһәр үзенең иле белән бергә Җучиләргә буйсынучы олыслар системасына кертелгән, ягъни Алтын Урда составына кергән. Аның беренче башкаласы итеп 1242 елда Батый хан Болгарны сайлаган.

XIII гасыр уртасында Болгар яңадан аякка баскан һәм монголлар тарафыннан үз империяләренең көнбатыш кырыйларында оештырылган яңа дәүләтнең әһәмиятле ноктасына әйләнгән.

XIII гасырда Болгар Алтын Урдада алдынгы рольне уйнаган. XIII гасырның 50 нче елларында рус, әрмән һәм болгар кенәзләре Батый ханга кенәзлек итү ярлыклары сорап килә торган булганнар. Соңрак, Мәнге Тимур, Бәркә хан һәм аеруча Үзбәк хан вакытында Болгар Алтын Урданың иң төп икътисадый, сәүдә, мәдәни һәм дини үзәкләренең берсе булып кала биргән. Монда XIII гасырның 60 нчы елларында Бәркә хан вакытында Җәмигъ мәчетен төзи башлаганнар. Ул Җучи олысында мондый беренче корылма булган. Болгар 1250 елларда Алтын Урданың бөек ханнары – Мәнге һәм Арык Бога исеменнән акча сугучы беренче шәһәре булган.



XIV гасырда, Алтын Урданың сәяси үзәкләре көньякка, Сарайга күчүенә карамастан, Болгар зур һәм куәтле шәһәргә әверелгән. Бу чорда шәһәр төньяк, көньяк, көнбатыш якларга шактый киңәйгән, туфрак өемнәреннән, агач диварлардан һәм манаралардан торган ныгытмалар рәте белән әйләндереп алынган. Ныгытылган өлеше 415 га тәшкил иткән.

Шәһәрнең Түбән Идел буе, Иран, Хәрәзем, Кавказ, Кырым, рус кенәзлекләре белән сәүдә элемтәләре киңәйгән. Күптармаклы махсус һөнәри җитештерү үсеш алган. Монда XIV гасырда ук, Көнбатыш Европададан 2 гасыр элек чуен коя башлаганнар. Монументаль архитектура корылмалары – сарайлар, феодал- аксөякләр йортлары, кәрван сарайлар, җәмигъ һәм квартал мәчетләре, мәктәпләр һәм мәдрәсәләр, җәмәгать мунчалары, төрбәләр һәм башка биналар: Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләр, Кара, Ак, Кызыл, Көнчыгыш пулатлар, Кече манара, Ханнар төрбәләре барлыкка килгән. Иң төп Җәмигъ мәчете яңадан корылган. Шәһәрнең төзеклеге югары дәрәҗәгә ирешкән. Күпер һәм сууткәргеч корылмалар, киптерү системалары төзелгән.

Урдадагы туктаусыз феодаль чуалышлар Болгарны әкренләп һәлакәткә алып барган. Шуларның берсе - Булат Тимернең 1361 елда Болгарга һөҗүме, ушкуйникларның һәм рус кенәзләренең XIV гасыр ахыры-XV гасыр башындагы һөҗүмнәре һәм, ниһаять, 1431 елда бөек кенәз Василий II тарафыннан җибәрелгән кенәз Федор Пестрый җитәкчелегендәге Мәскәү гаскәрләре һөҗүме шәһәрне һәлакәткә дучар иткән. Шул заманнан бирле Болгар тарихи аренадан мәңгегә юкка чыккан һәм мөселманнарның изге җиргә зыярәт кылу урыны гына булып калган. Биредә мөхтәрәм мөселманнар җирләнгән, руханилар һәм дәрвишләр яшәгән. Мәгълүм ки, XVI – XVII йөз татар шагыйрьләре Мөхәммәдьяр һәм Мәүлә Колый үз әсәрләрен Болгарда язганнар. XVI гасырда элеккеге Болгар дәүләте җирләре Рус дәүләте составына кертелгән.





# Җәмигъ мәчете











Җәмигъ мәчете. 1236 елдан соң ук башланган мөселман мәчете төзелеше XIII гасыр ахырында тәгәлләнгән. Мәчет Алтын Урданың тәүге чорыннан сакланып калган архитектура корылмасыннан гыйбарәт. XIII-XIV гасыр Болгарының иҗтимагый үзәген формалаштыручы комплексның төп бинасы. Элек ул 32 метрга 34 метр үлчәмдәге турыпочмак рәвешендә булган, эчке ягы дүрт кырлы 20 баганадан торган, дүрт кыеклы агач түбәсе булган. Мәчетнең барлык диварлары акшарланган, тышкы яктан таш баганалар белән ныгытылган. Гыйбадәтханәнең көньягында уеп ясалган бай бизәкле михраб урын алган. Формасы һәм төзелмәсе ягыннан әлеге мәчет 1973-1974 елларда Биләр шәһәрлегендә тикшерелгән монгол чорына кадәрге мәчеткә бик охшаш һәм күпрәтле терәкле, портал ишекле, ассиметрияле рәвештә ялганып төзелгән бер манаралы, заллы көнчыгыш мәчетләр тибына карый.

XIV гасыр башында мәчеткә зур реконструкция ясалган.Эчке ягы үзгәртеп корылган – гыйбадәт залы сигез кырлы алты нәфис колонналы алты өлешкә бүленгән, ике ишек һәм берничә тәрәзә уелган, почмакларына ялгап куәтле манаралар төзелгән. Төзелеш материаллары һәм төзү алымнары буенча Җәмигъ мәчете Кавказ арты, Кырым, Кече Азия, Месопатамия корылмаларын хәтерләтә. Шул ук вакытта анда, җирле табигать шартларын исәпкә алган хәлдә, Урта Азия архитектурасының стилистик үзенчәлекләре һәм төсмерләре дә чагылыш тапкан. Шул рәвешчә, стилистика ягыннан караганда, Җәмигъ мәчетенең архитектурасы, Болгар шәһәрлегенең башка истәлекләре кебек үк, көнчыгыш төзелеш сәнгатенең үзенчәлекле төньяк тармагын тәшкил итә.

2011-2012 елларда Җәмигъ мәчетендә зур конструкция эшләре үткәрелде, шул исәптән XX гасырның 60 нчы елларындагы реставрация вакытында куелган ясалма бетон блоклар алмаштырылды, мәчетнең үзенең туф блоклары торгызылды, эчендә ак таштан идәннәр түшәлде, уеп бизәлгән колонналары реставрацияләнде, михраб куышы яңадан торгызылды. Көнчыгыш почмактагы манара торгызылды, көнчыгыш һәм көнбатыш якларга таш баскычлар корылды.

# Олы манара















Мәчетнең төньяктагы төп фасадына аркалы ишек порталы һәм «Олы манара» буларак билгеле биек манара тоташкан. Россия тарихында үткән дәверләрнең архитектура корылмаларын саклауга юнәлтелгән беренче закон акты – Петр I нең борынгы Болгар истәлекләрен реставрацияләү һәм өйрәнү зарурлыгы турында  указы барлыкка килү нәкъ менә шушы манарага бәйле. 1722 елгы Фарсы походы вакытында император Болгар хәрабәләрен шәхсән үзе караган, алар анда зур кызыксыну уяткан.1722 елның 2 июлендә, Әстерхан шәһәренә җиткәч, император Казан губернаторы А.П.Салтыковка атап указ җибәргән, ул анда «Казан губерниясендә борынгы Болгар шәһәрлегендә татар манаралары дип аталган ике багананың нигезен төзәтүне» таләп иткән.

Олы манара төзекләндерелгән, ләкин безнең көннәргәчә сакланмаган, 1841 елда җимерелеп төшкән. Җимерелер алдыннан аны инглиз галиме Э.Турнерелли караган. Манара XIX гасыр үлчәм рәсемнәре буенча яхшы мәгълүм. Ул югарыдагы кече һәм түбәндәге зур цилиндрлардан торган 24 метрлы күләмнән гыйбарәт булган. Түбән цилиндрның төп көпшәсе аскы өлештә сигезкырлы ярус аркылы 5 метрга 5 метр зурлыктагы квадрат нигезгә үткәрелгән. Манара эчендә югарыдагы уратма галереялы, цилиндрлы катка менү өчен винтлы баскыч ясалган, ул зур булмаган алты тәрәзә белән яктыртылган. Болгарда шулай ук сакланып калган Кече манарадан аермалы буларак, Олы манара ике тапкыр биегрәк булган һәм фасадының урта биеклегендә гарәп язмасы - Корьән сүзләре уелган. Бу тарихи һәйкәл археологлар тарафыннан 1892, 1915, 1946 һәм 1964-1966 елларда тикшерелгән. Манара 2000-2002 елларда элеккеге үлчәмнәрдә торгызылган. 2011-2012 елларда манараның кече цилиндрын реконструкцияләү буенча эшләр башкарылды: аркалы декоратив тәрәзә уемнары ясалды, бакыр белән тышланды, уемлап ясалган бизәкле ишек куелды.

# Көнчыгыш төрбә











Көнчыгыш төрбә (Никола чиркәве) ак таштан, урта гасыр көнчыгыш мөселман төрбәләре тибында – чыгарылма порталлы итеп төзелгән. XIV гасырның 30 нчы елларында корылган. Эчке өлешендә ярымсфера рәвешендәге гөмбәзе бар. Диварның периметры буенча билгеле бер урыннарына балчык савытлар уелган. Портал уемы тоташтырылган керү өлеше көньякка юнәлтелгән. Бинаның турыпочмаклы формасы кыйшайту нәтиҗәсендә салмак кына сигез кырлы рәвешкә күчә. Туф кирпечләрдән төзелгән ярымсфералы гөмбәз яхшы сакланган.

Күләм-план төзелмәсе буенча Көнчыгыш төрбә - Урта Азия төрбәләренә, ә төзелеш материаллары, техник алымнар һәм деталь формасы буенча Кавказ арты һәм Кырым төрбәләренә охшаш.

1712-1735 елларда, Болгар шәһәрлеге территориясендә Успение монастыре булган чорда, Көнчыгыш төрбә православие храмына әйләндерелә. Бу тарихи ядкәр археологлар тарафыннан 1964-1966 елларда һәм 1991 елда тикшерелгән. Биредә Алтын Урда чорына караган агач һәм таш төрбәләрнең җидесенең сакланып калган өлешләре чистартылган, кайберләрендә күмелгән кешеләрнең сөякләре табылган. Реставрация эшләре 1967-1968 елларда үткәрелгән, ә 2011-2012 елларда төрбәнең нигезен ныгыту, уратма галерееяны урнаштыру буенча ашыгыч төзекләндерү-коткару эшләре башкарылды. Төрбәнең эчке һәм тышкы диварлары махсус эретмәләр белән эшкәртелде, нигезе төзекләндерелде. Объект музейлаштырылды – анда мультимедиа экзпозициясе булдырылды.

# Төньяк төрбә










Төньяк төрбә (Монастырь базы) Җәмигъ мәчетенең төп фасады каршында урнашкан. XIV гасырда ак таштан төзелгән бу бина XVIII гасыр тарихи чыганакларыннан мәгълүм. Планы буенча охшаш булса да, Көнчыгыш төрбәдән зуррак булуы һәм кайбер детальләре белән аерылып тора: ул тәбәнәгрәк, порталының нигезе озынрак, тавыш көчәйткеч җайланмалары торба рәвешендә түгел, күләмле савытлар рәвешендә корылган.

Төрбәнең иң беренче бинасыннан нигезе, эчке диварлары һәм аларның тышлыгы, тавыш җайланмалары, ишек һәм тәрәзә уемнарының очлы һәм аркалы рәвешләре, нигездән сигез кырлы формага күчүнең почмаклардагы кыеклары, гөмбәзнең түгәрәк нигезе, чыгарылма порталның калдыклары сакланып калган. Төрбә археологлар тарафыннан 1964, 1966 елларда тикшерелгән. Консервацияләү буенча төп эшләр XX гасырның 70 нче еллары башында үткәрелгән.

2011-2012 елларда бу ядкәрнең тышкы кыяфәтен элеккеге хәленә кайтару буенча төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды. Бетоннан эшләнгән саклагыч плита һәм металл баганалар сүтелде, гөмбәзнең тышкы кирпечләре ныгытылды. Эчке һәм тышкы диварлар, шулай ук нигез дә махсус эретмәләр белән эшкәртелде.

Төрбә эченә лапидарий урнаштырылды, VIII-XIV гасырлардагы Болгар эпиграфикасы күргәзмәсе - «Болгар эпиграфикасы» экспозициясе оештырылды, анда мультимедиа җайланмалар кулланыла. Бирегә куелган эпитафияләр Болгарның бөтен территориясеннән җыелган, кайбер плиталар Успение чиркәвен реконструкцияләгәндә табылган. Эпитафияләрнең тышкы күренешләре, уртак нәфис стиле борынгы Болгардагы таш уючыларның югары осталыгы турында сөйли. Лапидарий турында материал бирегә урнаштырылган мәгълүмат терминалына кертелгән. Яктырту системасы эшләнгән.

# Успение чиркәве









1732-1734 елларда төзелгән Успение чиркәве – биредә булган шул исемдәге монастырь корылмаларының сакланып калган бердәнбер гыйбадәт бинасы. Храм - Казан сәүдәгәре Иван Афанасьевич Михляев акчасына, чиркәү манарасы дин тотучылар акчасына төзелгән. 1341 елда чиркәү манарасы сүтеп алынган һәм 1862 елда бүгенге манара төзелгән. Чиркәүне төзегәндә аның нигезенә Болгар ядкәрләре харәбәләреннән алынган кабер ташлары салынган. Алар өстендәге гарәп һәм әрмән язмалары зур фәнни кыймматкә ия.

Провинциаль барокко стилендәге чиркәү XVII-XVIII гасырларда киң таралган «дүртлек өстендә сигезлек» тибына карый. Храмның төп өлешләре - ярымтүгәрәк абсидалы төп күләме, трапезная һәм чиркәү манарасы – бер күчәрдә, «корабль» рәвешендә урнашкан. Успение чиркәвендәге куб формасына охшаш зур төп күләмнең һәм дүртлекнең пропорцияләре гади, алар Урта Азия корылмаларын хәтерләтә. Бизәлеше тыйнак. Архитектура бизәлешенең төп элементлары - кәрниз һәм тәрәзәләрнең ярымбаганалы, сынык фигуралы сандриклы кысалары. Төзүчеләр элеккеге корылмаларның – мәчет белән манара һәм төрбәләрнең композициясен күздә тотып, сәнгати бердәмлек принцибында эш иткәннәр.

1965, 1977, 1982-83 елларда чиркәүгә реставрация ясалган. 2010-2011 елларда фундаменты ныгытылды, идән яңабаштан, таштан түшәлде, түбә яңадан ябылды, тәрәзә блоклары, җылыту һәм электр белән тәэмин итү системасы алмаштырылды. Янгыннан саклау сигналы системасы, видеокүзәтү җайланмалары куелды. Биредә «Болгар авылы һәм Спас өязе тарихы» экспозициясен оештыру буенча эш алып барыла.

# Кара пулат







Кара пулат – Алтын Урда чоры Болгарының (XIV гасыр) безнең көнгә кадәр иң тулы сакланган биналарының берсе. Ул туфтан һәм известьташтан төзелгән. Бу дүрт катлы корылманың түбәсе купол рәвешендә куелган. Аскы кат кырыйларында зур булмаган бүлмәләр урын алган. Һәрбер катның бөтен дүрт диварына тәрәзәләр уелган. Дүртенче кат сигезпочмак рәвешендә төзелгән. Икенче катның гөмбәзле, тәрәзәле залы сәнгати бизәлгән: штукатурланган диварларда гипска бизәкләр уелган, баскычларга кысалар ясалган, тәрәзәләргә рәшәткәләр куелган.

Берничә катлы бердәм архитектура комплексыннан бары тик үзәк өлеш һәм аның интерьер кисәкләре генә сакланган. Деталь билгеләре буенча ( төзелеш материалын исәпкә кертмичә) Кара пулат Урта Азиянең XIV гасыр корылмаларына якын тора. Көнчыгыш төзелеш сәнгатенең сакланып калган истәлекләреннән Бакудагы Диванханә аның баштагы кыяфәтенә охшаган. Чыганаклардан күренгәнчә, ул ханның хөкем итү урыны булган.

XVIII гасырда монда монастырьның монахлар төзегән ыслау йорты булган. Бәлки аның исеме дә шуннан килеп чыккандыр. Кара пулатның сакланып калуы нәтиҗәсендә XIX гасырның 70 нче елларында, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте биредә борынгы әйберләр музее оештырган. Монда кабер ташлары, Болгар җимерекләрендә табылган зур архитектура детальләре җыелган. Кара пулат археологлар тарафыннан 1957 һәм 1966 елларда тикшерелгән. Палатага реставрация 1884-1926, 1956, 1976, 1987 елларда ясалган. 2010-2011 елларда бу үзенчәлекле истәлектә - Болгарда сакланып калган бердәнбер гражданлык бинасында гидроизоляция һәм гидрофобизация, уратма галереяның консервация кирпечен сүтү буенча киң колачлы эшләр башкарылды.

# Ак пулат














Ак пулат. Әлеге монументаль бинаның тышкы кыяфәте академик П.С.Палласның 1768 елгы тасвирламасы буенча мәгълүм. Бу һәйкәл XIX гасырның 60 нчы елларында җимерелеп төшкән, шулай да аның XVIII гасыр ның икенче яртысында–XIX гасырның беренче яртысында ясалган күпсанлы рәсемнәре сакланып калган. Ф.Эрдманның XIX гасырның 20 нче елларындагы, П.П.Свиньинның 1823 елгы рәсемнәре, А.Шмидтның 1827 елгы планы,сызымнары, Н.Н. һәм Н.Г.Чернецовларның 1838 елгы рәсемнәре, ә соңрак А.К.Саврасов, И.И.Шишкин сәнгати әсәрләре иң яхшылардан санала.

Әвернә формасындагы бай бизәлешле бу бина мунча ролен үтәгән, гөмбәзле үзәк залдан, киенү-чишенү бүлмәсеннән, юыну бүлмәләреннән һәм җылыту, мич ягу бүлмәсеннән гыйбарәт. Көнчыгышта мунчалар, шул исәптән Болгарда да санитар ролен генә үтәмәгәннәр. Алар эшлекле әңгәмәләр алып барыла, сәүдә килешүләре төзелә торган ял итү урыны да булган.

Ак пулатта яңа археологик тикшеренүләр XX йөзнең 80 нче елларында үткәрелгән. Галимнәр цивилизацияле Көнчыгыш стандартларына туры килә торган җылыту мичләрен, кайнар пар йөрү каналларын, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү һәм файдаланылган суның агызу системаларын тапканнар.


Янәшәдә казылган 10-12 м тирәнлектәге өч кое мунчаны су белән тәэмин иткән. Тикшеренүче белгечләр 1877 елгы казу һәм төзекләндерү эше эзләре тапканнар. Шул вакытта Ак пулатта таш фонтаннар,сулыклар казып чыгарылган, алар хәзерге көндә музейга куелган. 1990 елларда әлеге ядкәргә консервация ясалган. 2012 елда диварлары сүтелеп, элек концервацияләнгән өлешкә тәңгәл китереп торгызылды, гөмбәз астындагы почмакларга блоклар куелды, бөтен комплекс чыланудан саклый торган гидрофобия составы белән капланды, нигезләргә гидроизоляция ясалды.

# Кече манара













XIV гасырның икенче яртысында төзелгән Кече манара 1712 елгы чыганакларда телгә алына. Ул 16 метрлы таш күләмнән гыйбарәт. Аркалы ишек һәм орнаментлы куыш бик бай бизәлгән, биредә таштан уюның нәфис техникасы кулланылган. Бизәлеш эзләре өске галереяда да сакланган, аңа винтлы таш баскыч алып менә.


Бу манара шәһәрлекнең үзәк өлешендә урнашкан манарадан тәбәнәгрәк булганы өчен Кече дип аталган. Ул мөселманнар өчен аеруча изге урын санала. Татар мөселманнарының Болгардагы борынгы манара һәм мәчетләр янында вафат булганнар рухына дога кылу традициясе бар.

2010 елда “Зенит банклар группасының” борынгы Болгар шәһәренең һәм Зөя утрау-шәһәренең тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызуда һәм аларны тиешле тәртиптә тотуда катнашуы турында меморандумга кул куелды. 2011 елда банк акчасына Кече манарага реставрация ясалды: диварларын чистарту һәм ныгыту буенча төзү-реставрация һәм консервация эшләре башкарылды, гөмбәзе бакыр белән ябылды. Бу тарихи ядкәрнең керү өлеше һәм ишек өстендәге декоратив бизәкнең бер өлеше реконструкцияләнде.

Инвестор:
«Зенит банкы» ААҖ.
Директорлар советы рәисе А.А.Соколов.

# Ханнар төрбәсе









Кече манарадан төньяк юнәлештә өч төрбәнең хәрабәсе сакланган, аларның берсе Ханнар төрбәсе дип атала. Ханнар төрбәсе – XIV гасыр-XV гасыр башындагы архитектура биналары комплексының бер өлеше, бу биналар көнчыгыштан көнбатышка таба бер сызыкта яталар, алар XVIII гасыр чыганакларыннан мәгълүм. Комплекс археологлар тарафыннан 1914 елда һәм 1968-1969 елларда тикшерелгән. Төрбәнең янкормасында мич һәм җылылыкны идән астыннан алып баручы каналлар табылган. Төрбәдә консервация-реставрация эшләре 2005-2006 елларда үткәрелгән.

Шул ук вакытта әлеге районда Кече манарадан көньякка һәм көнчыгышка таба, XIV гасыр ахыры-XV гасыр башына караган архитектура корылмаларының нигезләре ачылган. Җылыту системасы калдыкларына карагандa, алар төрле зурлыктагы төрбәләрдән генә түгел, башка максатларда кулланыла торган биналардан да гыйбарәт. Аларның барысына да консервация ясалган һәм алар карау өчен ачык. Төрбәләрнең таш биналары, алар эчендәге кирпечтән корылган кабер ташлары һәм төрбәләр моның аксөякләр төрбәсе булуы турында сөйли.

2011-2012 елларда реставрация ясаучылар төрбәнең көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләренә соңрак куелган бетон блокларны һәм цемент ярдәмендә тезелгән кирпечләрне сүттеләр һәм Көнбатыш төрбәнең диварлары, киселгән таш тезеп, элек консервацияләнгән өлешкә тәңгәл итеп торгызылды. Көнчыгыш төрбә диварларын бут кирпиченнән төзеделәр, Үзәк төрбәнең гөмбәзен чистарттылар, комплексны чыланмый торган гидрофобия составлары белән эшкәрттеләр.

---

Инвесторлар:
Татарстан Республикасының Актаныш районында яшәүчеләр.



# Көнчыгыш пулат









Көнчыгыш пулатны кайвакыт Хан мунчасы дип тә йөртәләр. Ул шәһәр мунчасының хәрабәләреннән гыйбарәт. XIII гасырда төзелгән әлеге кирпеч-таш бина – җәмәгать мунчасы XVIII гасыр чыганакларыннан мәгълүм. Бүлмәләренең эчке төзелеше, инженерлык җайланмалары булганлыкның эзләре (идән астыннан җылыту, төтен чыгу юллары, су, канализация системалары) күренеп тора. Тулаем алганда, ул Кызыл пулат, аеруча Ак пулат конструкциясен хәтерләтә. Бу шәһри Болгарның иң зур, иң борынгы җәмәгать мунчасының калдыклары булып санала.

Биредә археологлар 1983-1993 елларда казу эшләре алып барганнар. Бүлмәләрне чистартканда табылган нумизматика әйберләренең анализы бинаның төзелеш һәм кулланылыш вакытын ачыкларга мөмкинлек биргән. Мунчаның XIII йөзнең 90 нчы еллары башында ук актив кулланылуы һәм XIV йөзнең 30-40 елларына кадәр эшләве ачыкланган. Биредә консервация-реставрация эшләре 1990 нчы еллар ахырында һәм 2011-2012 елларда үткәрелгән. Диварлары, киселгән таш тезеп, элек консервацияләнгән өлешкә тәңгәл рәвешкә китерелде, юкка чыккан почмак блоклары, бинаның гөмбәзе астындагы өлештә плинфадан һәм таштан түшәлгән идәннәр торгызылды, җылыту каналлары һәм җылылк йөрү юллары реконструкцияләнде.

# Хан сарае





XIV гасырның беренче яртысында Болгар архитектура истәлекләренең үзәк комплексы тулысынча формалашкан, аңа Хан сарае – почмакларында багана-пилоннары булган монументаль корылма да кергән. Бу - турыпочмак рәвешендәге (эчке үлчәмнәре 24 метрга 29 метр) бина, шәһәрлекнең өске платосы кырыенда, Җәмигъ мәчетеннән төньяк-көнчыгышка таба, Кызыл пулат өстендә урнашкан. Ул төньяктан көньякка сузылган, почмакларында түгәрәк баганалары булган турыпочмаклы формадагы кирпеч-таш корылма калдыкларыннан гыйбарәт. Бу Үзәк Азия, Иран, Һиндстан сарай комплексларына хас типик ансамбль.

Казу эшләре ачыкланганча, бина көнбатыш дивары астыннан төньяктан көньякка таба үтә торган элеккеге оборона чокыры урынында төзелгән. Ул чордан диварлар, вак буттан төзелгән, өстенә известь измәсе коелган нигезләр, цоколь сакланып калган. Диварның тышкы ягы - бик яхшы тезелгән ак таш блоклардан, эчке ягы – кирпеч плинфадан төзелгән, үзәк өлеше бут кирпечләреннән известь измәсе кулланып ясалган. Аннан соңгы чорда михраб урынына көньяктан зур тамбур рәвешендә ишек тоташтырылган.

Бу бинада археологлар 1994 елда казу эшләре алып барганнар, 1000 кв метрдан артык җирне ачканнар. Биредә табылган





әйберләр Хан сарае төзелешенең XIII гасыр уртасында башлануын раслый.


Тикшерену барышында объектның 1227 елдан Алтын Урданың хакиме, Җучи улы, Чыңгыз хан оныгы булган Батый хан (1208-1255) сарае комплексына керүен раслый торган дәлилләр табылган.

Комплексның үзенчәлеге һәм табылдыклар шуны раслап тора. Анда XIII гасыр уртасына караучы әйберләр, шул исәптән 1240-1259 елларда сугылган тәңкәләр табылган.

2011-2012 елларда «ТСНРУ» белгечләре сакланып калган нигезләрне консервацияләү, бинаның юкка чыкан элементларын өлешчә реконструкцияләү буенча эшләр башкарды: тышкы диварлар һәм почмактагы баганалар ак таш блокларның 1 нче - 3 нче рәтенә кадәр күтәрелеп, плинфа кирпечләрдән тезелгән эчке диварга тоташтырылды, археологлар казып чыгарган корылмаларның һәм бинаның эчке өлешенең фрагментлары музейлаштырылды.

Комплекс өстенә «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе проекты буенча саклагыч конструкция куелды, ул гомуми мәйданы 2000 кв м булган япмадан гыйбарәт. Саклагыч корылманы «Алексеевскдорстрой» ААҖ (генераль директоры Ф.В.Вәлиев) һәм «Стройдорсервис» ААҖ (директоры И.И.Зайдаров) подрядчы оешмалары әлеге уникаль ядкәрне табигать шартларыннан саклау максатында, заманча технологияләрне кулланып, ЮНЕСКО таләпләренә туры китереп төзеде. Япманың материалы - Казанның «СафПласт» заводында эшләнүче монолит поликарбонат.









# Болгарда археология тикшеренүләре









Дөнья цивилизациясендә халыклар һәм культуралар даими һәм күптөрле рәвештә үзара тәэсир итешкән берничә төп төбәк бар. Идел буе шундый төбәкләр исәбенә керә. Нәкъ менә биредә күп халыкларның тарих сәхифәләре, тиңсез энже бөртекләредәй, күп гасырлар буе бер-берсенә йогынты ясап, бер җепкә тезелеп барганнар.

Идел буе төбәген өйрәнү – глобаль тарихи-мәдәни, цивилизация проблемасы. Ул фәннәрнең һәм фәнни эзләнүнең мөстәкыйль юнәлешләренең бөтен бер спектрына бәйле. Безнең заманда - дөньяның бөтенлеген җимерүче деструктив факторларның тәэсире әле көчле булганда, дөньяны берләштерү юлларын эзләү һәм табу гаять әһәмиятле. Моның мәгънәсе бик тирән.

Узган заманнарда биредә яшәгән халыкларның, безнең якның тарихының һәм мәдәниятенең зур кызыксыну уятуы закончалыклы күренеш. Идел буе тарихы драматик коллизияләргә һәм борылышларга бик бай, бу, иң беренче чиратта, әлеге урында борынгы заманнардан ук аралашу зоналарыннан һәм цивилизацияләр кисешүеннән торган чын төен барлыкка килү белән билгеләнгән. Бу «эретү казанында» узган чорларның күп кенә мәдәниятләре һәм бөек дәүләтләре барлыкка килгән, алар Евразия цивилизациясе үсешенә зур өлеш кертәннәр һәм аның аерылгысыз өлеше булып торалар. Шуңа күрә тарихи процессларны, төгәлрәк әйткәндә, Урта гасырлар дәверен өйрәнү хәзерге замандагы проблемалы вәзгыятьләрнең чыганакларын ачыкларга мөмкинлек бирә ала.

Һичшиксез, Идел буе төбәген комплекслы өйрәнү зур фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия һәм Россиянең, дөньяның күп шәһәрләреннән төрле белгечләр арасында тыгызрак элемтәләр урнашуга закончалыклы рәвештә ярдәм итә. Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясенең, Россия Фәннәр академиясенең, аларның институтларының һәм бүлекчәләренең, Казанда дәүләт структуралары ярдәме белән яңадан оештырылган федераль университетның бердәм эшчәнлеге нәтиҗәсендә комплекслы фәнни тикшеренүләр гамәлгә ашырыла.

Күп гасырлар элек булган реаль вакыйгаларның шаһитләре – сакланып калган хәрабәләрнең элек-электән сәяхәтчеләр, табигатьне өйрәнүчеләр, рәссамнар, колеекциячеләр һәм хәзинә эзләүчеләр игътибарын җәлеп итүе гаҗәп түгел. Хәзинә эзләүчеләр исә биредә сакланып калган биналарның кирпечләрен сүтеп, борынгы әйберләр табып сатуны табышлы кәсепкә әйләндергәннәр. Моның белән алар әлеге борынгы ядкәрләрнең җимерелүен һәм юкка чыгуын тизләткәннәр.


Болгар шәһәрлегенең һәм аның истәлекләренең беренче тулы тасвирламасы 1712 елга карый, ул чакта дьяк Михайлов, биредә Успение ирләр монастыре оештырылуга бәйле рәвештә, бу ядкәрләрнең исемлеген төзегән. Ун елдан соң, Идел буйлап баручы патша Петр I шәһәрлеккә туктаган һәм хәрабәләрне караганнан соң таш корылмаларны саклау чараларын күрергә кушкан.

Шәһәрлектә системалы тикшеренү эшләре 75 ел элек, 1938 елда А.П.Смирнов җитәкчелегендә башланган, бу Болгар шәһәренең төрле чорларының тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре, шул исәптән социаль топографиясе, территориясенең үсеш динамикасы, төзелеше, һөнәрчелеге, сәүдә тармагы, төзекләндерү эшләре һ.б. буенча зур һәм күптөрле материал туплауга мөмкинлек биргән.

2010 елдан башлап, Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш.Шәймиев тәкъдиме буенча, эшчәнлеге Болгар музей-тыюлыгы, «Свияжск утрау-шәһәре» музее, Татарстан территориясендәге башка тарихи һәм мәдәни истәлекләр үсешенә ярдәм итүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды оештырылгач, әлеге бурычларны үтәү буенча киң колачлы эшләр алып барыла.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында 2010-2011 елларда Болгар шәһәрлегендә казу эшләре алып барылды. Алар музейлаштыру һәм тарихи истәлекләр торган территорияләрне төзекләндерү буенча эшләр барган урыннарда җимерелеп баручы мәдәни катламны өйрәнүгә юнәлтелгән иде.

Археология тикшеренүләре ТР Фәннәр Академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты җитәкчелегендәге Археология тикшеренүләренең милли үзәге тарафыннан, Казан федераль университеты, Россия Фәннәр академиясенең Археология институты һәм башка фән һәм мәгариф учреждениеләре белгечләре белән бергәләп алып барылды. Белгечләрдән тыш, казу





# Болгарда археология тикшеренүләре







эшләрендә Татарстаннан һәм башка төбәкләрдән студентлар һәм мәктәп укучылары катнашты.

Киң колачлы археологик тикшеренүләр Көнчыгыш Европаның урта гасырлардагы матди культурасының формалашуы һәм үсеше тарихы буенча кызыклы материал бирде. Тикшеренү эшендә өйрәнүнең заманча ысуллары киң кулланыла. Тирәюньгә зыян китерми торган геофизик һәм дистанцион аэрокосмик ысуллар ярдәмендә яңа нәтиҗәләргә ирешелде. Әлеге ысуллар мәдәни катлам астында ятучы күп кенә монументаль таш биналарның урынын төгәл билгеләргә мөмкинлек бирде. Палеоэкологияне реконструкцияләүгә юнәлтелгән фәнни-табигый ысуллар комплексы ярдәмендә матди культура әйберләрен өйрәнү, урта гасыр эшләнмәләрен ясауның технологик үзенчәлекләрен ачыклау һәм шулай ук урта гасырларда Болгарда яшәүчеләрнең антропогенетикасын өйрәнү фәнни тикшеренү эшендә яңа сәхифә ачты.

Тупланган материал 2010-2011 елларда Болгар тарихындагы һәм мәдәниятендәге инде яхшы мәгълүм кебек тоелган фактлар турында бик күп яңа нәрсәләр белергә, шулай ук урта гасырлар шәһәренең төзелеше һәм планиграфиясе турындагы элеккеге күзаллауларны үзгәртергә мөмкинлек бирде. Бу Болгар территориясендә археология тикшеренүләрен шактый зур мәйданда алып бару нәтиҗәсендә мөмкин булды. Фәнни тикшеренүләрнең гомуми күләме: шәһәрлек территориясендә 20 мең кв. м тирәсе археологик казу урыны. Моны гамәлгә ашыруда якынча 150 белгеч һәм лаборант катнашты, өске мәдәни катламнарны ачуда эшчеләр сыйфатында республиканың һәм башка өлкәләрнең төрле оешмаларыннан якынча 800 кеше эшләде.

Археология тикшеренүләренең соңгы өч елы эчендә Болгарның урта гасырлардагы тарихы турында уникаль мәгълүмат җыелды. Казу эшләре барышында шәһәрлек территориясендә, аның үзәк өлешендә торак йортлар салынган районнар ачылды, йортларның калдыклары табылды. Бу елларда казу эшләре алып барылган зур объектларның берсе - Хан сарае бинасы. Шәһәрлекнең үзәк өлешендә тикшерелгән зур монументаль биналар исәбенә елга вокзалы янында табылган таш мунча калдыклары да керә.

Үзәк өлештәге тикшеренүләрдән тыш, казу эшләре зур шәһәрлекнең башка урыннарында да алып барылды. Шәһәрлекнең көньяк кырыенда, Кече шәһәрлектә казулар нәтиҗәсендә XIV гасыр уртасына караган ак таш бина калдыклары ачылды. Болгарның Көньяк капкасы янында XIV гасырга караган зур таш төрбә нигезенең калдыклары табылды. Урта гасыр зиратларындагы каберләр мөстәкыйль тикшеренү объекты булып тордылар, алар шул замандагы күмү йолалары турында кызыклы материал бирде.

Планлы эшләр барышында Галанкино күле тирәсендә табылган чүлмәк ясау мичләренең калдыклары ачылды.

Фәнни тикшеренүләр нәтиҗәсендә табылган корылмалар планлы рәвештә өйрәнү һәм реставрацияләү объектлары булдылар. Казып табылган объектларны саклау максатында, әлеге корылмалар консервацияләнеп кенә калмады, алар өстенә саклагыч корылмалар да эшләнеп куелды. Бу исә борынгы корылмаларны саклап кына калмый, тарихи ядкәр тирәсендә туристлар өчен яңа тарихи-мәдәни тирәлек тудыра.

Комплекслы тикшеренүләрнең нәтиҗәләре тарихи белемнең яңа дәрәҗәсен булдыруга һәм археология фәненең әһәмиятен тулаем арттыруга нигез булачак. Киләчәккә перспективаларны һәм тарихи территорияләрнең, иң беренче чиратта Болгарның мөмкинлекләрен исәпкә алып, археологлар эшчәнлеге өчен тиешле шартлар тудырыла.

Болгарда археологлар өчен махсус комплексның төзелеше тәмамланды. Бу заман таләпләренә җавап бирүче фәнни база булачак, ул халыкара фәнни тикшеренү буенча хезмәттәшлекнең зур үзәгенә әвереләчәк.

---

Инвестор:
«Газпром» ААҖ.
Идарә рәисе А.Б.Миллер.

Подрядчы оешма:
«Грань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять.
Генераль директоры Л.В.Анисимов.











# Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда исламны дәүләт дине буларак кабул итүе хөрмәтенә истәлек билгесе










2012 елның 21 маенда Болгарда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиеа, ТР Премьер-министры Илдар Халиков, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти Тәлгать Тажетдин катнашында, Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда исламны дәүләт дине буларак кабул итүе хөрмәтенә истәлек билгесе тантаналы рәвештә ачылды.

Идеянең авторы - «Акибанк» ААЖ идарәсе рәисе Илдар Галәүтдинов. Истәлек билгесенең инвесторлары: «Татэнерго» ААЖ, «Акибанк» ААЖ, проектны эшләүче – «Татинвестграждан проект» ДУП, генераль подрядчы – «Грань» ҖЧҖ. Бу - 25 метр биеклектәге сигез кырлы, зур, түгәрәк титанит гөмбәзле, борынгы Болгар архитектурасы стилендә төзелгән бина, өстенә ярым ай куелган. Тышлау өчен таш Италиядән кайтарылган. Гөмбәзле залны Коръән сүрәләренең классик каллиграфиясе бизәп тора. Аның авторы - хәттат (каллиграф) Рамил Насыйбуллин.

Үзәк залда махсус пьедесталга Илдар Галәүтдинов тәкъдиме буенча Италия осталары тарафыннан эшләтелгән Коръән куелган. Бу үзенчәлекле басма сәнгати яктан югары дәрәҗәдә башкарылу сәбәпле РФ Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәни хәзинә дип танылды. Истәлек билгесенә урнаштырылган Коръән - мөселманнарның изге китабының дөньядагы иң зур басма үрнәге, бу Гиннесс






# Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда исламны дәүләт дине буларак кабул итүе хөрмәтенә истәлек билгесе











рекордлары китабының сертификаты белән расланган. Аның үлчәмнәре бик зур: буе – 2 м, иңе -1,52 м, авырлыгы – 800 кг. Асылташлар һәм ярымасылташлар белән бизәлгән. Корьәнне эшләгәндә малахит платиналар, сусаль алтын, көмеш, фирүзә, коралл, куе яшел авантюрин, аметист, циркон, лазурит, кызыл яшма, топаз кулланылган.

Зал диварына Әл-Мөктәдир хәлифә илчелегенең Болгарга юлын күрсәтүче өч үлчәмдәге карта куелган. Аны архитектор Рөстәм Габбасов доломит, кабырчык токым, мәрмәр һәм металл кулланып эшләгән.

Аскы катта картиналар галереясы урнашкан, анда Татарстан рәссамнарының йөздән артык картинасы куелган. Бирегә күргәзмәләр һәм конференцияләр уткәрү өчен музей-күргәзмә комплексы да бар. Комплексның экспозициясендә археологларның табылдыклары, язма чыганакларның төп нөсхәләре һәм кучермәләре, нумизматика, зәркәнчелек эшләнмәләре, шулай ук рәсем сәнгате үрнәкләре, шул исәптән мозаик панно да куелган. Панноның эскиз авторы һәм рәссамнар төркеме җитәкчесе Фәрит Вәлиуллин. Бу панно 922 елда Идел буе болгарларының исламны дәүләт дине итеп кабул иткән көнне һәм Болгар ханы Алмышның Багдад хәлифә илчеләре белән очрашу тантанасын тасвирлый.







Бу вакыйганың төп һәм иң мөһим чыганагы – Идел буе Болгар дәүләтенә абассид хәлифәсе Әл-Мөктәдир илчелеге белән килгән Әхмәт Ибне Фадланның «Идел буена сәяхәт турында язмасы». Илчелек Багдадтан 921 елда кузгалган, Идел буе Болгар дәүләтенә 922 елның маенда килеп җиткән. Ибне Фадлан бу сәяхәт турында җентекләп язган, аның «Язма» сында уникаль тарихи һәм этнографик мәгълүмат китерелгән. Ибне Фадланның «Язмасы» татар, рус, гарәп, алман телләрендә нәшер ителеп Истәлек билгесенең экспозициясенә куелган.

Инвесторлар:
«Татэнерго ААҖ.
Генераль директоры И.Ш. Фәрдиев.

«Акибанк» ААҖ.
Идарә рәисе И.Х.Галәүтдинов.

Подрядчы оешма «Грань» ҖЧҖ.
Генераль директоры Л.В.Анисимов.


GUINNESS WORLD RECORDS

CERTIFICATE

The largest printed Koran measures
2 m (6 ft 6.74 in) high,
1.52 m (4 ft 11.84 in) wide
and 0.17 m (6.69 in) thick
and was created by ARC Group s.r.l. (Italy),
Nedjan Bratačevec and Andrej Cernatič
(both Slovenia) and Mauro Loca (Italy).
It was presented by the Republican Foundation
for the Revival of Historical and Cultural
Monuments of the Republic of Tatarstan
(Russia) to the Kul-Sharif mosque, Kazan,
Republic of Tatarstan, Russia,
on 17 November 2011

GUINNESS WORLD RECORDS

# Ак мәчет









2012 елның 10 июнендә киң җәмәгатьчелек катнашында, ел саен үткәрелә торган «Изге Болгар җыены» көннәрендә тантаналы төстә Ак мәчет ачылды. Архитектор Сергей Шәкүров проекты буенча төзелгән

Ак мәчет ансамбленә мәчет үзе, мөфти хәзрәтләренең резиденциясе һәм мәдрәсә керә. Мәчетнең гыйбадәт мәйданы - мусалла 88 колоннадан торган арка белән әйләндереп алынган, үзәгендә фонтан төзелгән. Арканың ачыклыгы нәтиҗәсендә биргә килүчеләр табигать матурлыгын да, борынгы Болгардагы археологик казылмаларны да күрә ала.





# Ак мәчет









Мәчет үзенең геометрик орнаменты, уеп ясалган бизәкләре, интерьерлары нәфислеге, гомуми стилистикасы белән белән таң калдыра. Гыйбадәт бүлмәсенең мәйданы - 180 квадрат метр. Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, бөтен дөнья мөселманнарының зыярәт кылу урыны булган Мәдинә шәһәрендәге Мөхәммәт пәйгамбәр мәчете манараларына охшатып ясалган 46,5 метр биеклектәге ике манара мәчетнең төп бинасын бизәп тора. Төп бина гөмбәзенең диаметры - 10 метр, эчке биеклеге - 17 метр, ул традицион декоратив элементлар белән бизәлгән. Төзелешендә 1200 тонна мәрмәр кулланылган. Мәчетнең ак төсе тынычлыкны һәм ниятләр чисталыгын сынландыра.

Мәчет алдындагы мәйданда күл ясалган, аның тигезлегендә гүзәл Ак мәчет тулсынча чагылып тора.

---

Инвесторлар:
«Металлоинвест» холдингы.
Нигез салучысы - Әлишер Усманов.

«Развитие Украины» хәйрия фонды.
Оештыручысы Ринат Әхмәтов.

«Татнефть» ААҖ.
Генераль директоры Шәфәгать Тәхаутдинов.

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы.
Генераль секретаре Әкмәледдин Ихсаноглы.

Подрядчы оешма «Грань» ҖЧҖ.
Генераль директоры Л.В.Анисимов.






# «Икмәк музее» музей-туристлык комплексы









2012 елның 21 маенда Болгарда «Икмәк музее» музей-туристлык комплексы ачылды, ул Татарстан җирендә иген игү һәм икмәк пешерүнең борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәр тарихын күрсәтеп тора. Музей комплексында игенчелекнең иген үстерүдән башлап ипи пешерүгә кадәр бөтен циклы чагылдырыла, татар авылы колоритын саклаган хәлдә болгарларның һәм Казан татарларының көнкүреше һәм хуҗалык итү үзенчәлекләре күрсәтелә. Гомуми мәйданы – 5 гектар тирәсе.

Икмәк музее составына төп экспозиция, җил һәм су тегермәннәре, тегермәнче йорты, амбар, ындыр табагы, икмәк пешерү йорты, тимерче алачыгы, һөнәрче осталарның сәүдә рәтләре керә.

Икмәк музееның төп экспозициясе төп бинада, 320 кв м мәйданда урнашкан. Биредә Татарстан халыклары тормышында икмәкнең ролен күрсәтүче экспонатлар куелган.





# «Икмәк музее» музей-туристлык комплексы









Төп экспозиция игенчелек һәм икмәк житештерүгә бәйле матди һәм рухи культураның үсеш тарихы, милли традицияләр, Татарстанның данлыклы игенчеләре династияләре белән таныштыра.

Бронза, борынгы тимер дәверләренә һәм борынгы урта гасырга караган уникаль экспонатлар беренче игенчеләр узган катлаулы юлны – таяк көрәктән һәм китмәннән башлап сукалы игенчелеккә кадәр чорны күрсәтеп торалар. Авыл хуҗалыгы эшләренең төрләре агрономия өлкәсендәге белем, игенчеләрнең күнекмәләре эволюциясе белән бергә, коралларның һәм техниканың кул җайланмаларыннан, җигүле кораллардан машиналарга кадәр үсеше аркылы күрсәтелә. Икенче зал Татарстан территориясендә икмәк җитештерүнең борынгы заманнардан башлап XXI гасыр башына кадәр тарихы белән таныштыра.

Экспозицияләр музей комплексының башка биналарында да оештырылган.

---

Инвесторлар:
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җитәкчелегендә агросәнәгать предприятиеләре.
Министр М.Г.Әхмәтов.





# Табиб йорты
# Һөнәрчелек остаханәләре







2012 елның 5 октябрендә шәһәрлекнең үзәк өлешендә Россиядә бердәнбер булган гарәп-мөселман медицинасы музее – Табиб йорты ачылды. Төзелешнең инвесторы – «Русский стандарт» холдингы (идарә рәисе Рөстәм Тарико). Музейның фәнни концепциясенең төп максаты - Болгарның һәм Идел буе Болгар дәүләтенең фәннәр, атап әйткәндә медицина, табигать белеме, фармакология, шулай ук әлеге тармакларга бәйле һөнәрләр үсеше үзәкләренең берсе булларак ролен чагылдыру.

Экспозициянең төп темасы - Идел буе Болгар дәүләтеннән булган урта гасыр табибы Таҗетдин Әл-Болгари хезмәтләре. Ул мөселман дөньясына яхшы мәгълүм булган. Таҗетдин Әл-Болгари кулъязмалары – «Әт-тиръяк әл-кабир» (Зур тиръяк), «Әл-әдвия әл-мофрад»(Бердәнбер дару) һәм «Мохтәсар фи мәгърифә әл-әдвия» (Даруларны белү өчен кыска китап). Аларның күчермәләре Иран һәм Төркия музейлары һәм китапханәләре фондларыннан һәм саклагычларыннан кайтарылды.

Инвестор:
«Русский стандарт» холдингы.
Президенты Рөстәм Тарико.





Алтын Урда чорында шәһәрнең үзәк өлешендә, Җәмигъ мәчете янында шәһәр базары, ә анда сәүдә-һөнәрчелек рәтләре булган. Галимнәр билгеләп үткәнчә, археологик казулар вакытында шактый күп нумизмат материал белән бергә чимал, ярымфабрикатлар, сөяк, пыяла, гипс, төсле металлдан эшләнмәләр һәм аларны эшкәртү кораллары да табылган. Һөнәрчелек остаханәләре булдыру - музей-туристлык комплексы үсешенең чираттагы этабы, аның төп бурычларының берсе - борынгыдан ук килгән традицион һөнәрләрне саклау һәм популярлаштыру буенча эш алып бару. «Русский стандарт» холдингы акчасына төзелгән бу бинада хәзерге заман осталарына житештерүне оештыру һәм музейга килүчеләр өчен интерактив дәресләр үткәрү өчен барлык шартлар тудырылган. Бирелә мастер-класслар һәм Болгарның традицион технологияләрен торгызучы чүлмәкчеләр, металл, күн, агач эшкәртү осталарының сәүдә киосклары урнаштырылган.

Инвестор:
«Русский стандарт» холдингы.
Президенты Рөстәм Тарико.









# Елга вокзалы





Музей комплексы белән кушылган Елга вокзалы Болгар шәһәрлегенә чиктәш территориядә, Идел ярында урнашкан.

Комплексның төп вазыйфасы – елга транспорты белән килүче туристларны кабул итү. Аның эчке структурасы вокзал бинасын һәм Болгарның тарихына һәм мәдәниятенә багышланган музей экспозицияләренең берничә катын үз эченә ала. Бинаның архитектура образы традицион Болгар мәдәниятенең мотивларын чагылдыра. Елга вокзалының өч манарасы Болгар дәүләтенең өч зур шәһәре – Болгар, Сувар һәм Биләр образларының символы булып тора. Сувар һәм Биләр манараларында Идел буе Болгар дәүләте удел кенәзлекләре үзәкләренең тарихы буенча мәгълүмат һәм материаллар куелган күргәзмә павильоннары урын алачак.

Болгар музей-тыюлыгының, Татарстанның һәм Россиянең музей җыелмаларының аерым әһәмияткә ия колекцияләренә нигезләнгән Болгар цивилизациясе музее борынгы Болгарның болгар цивилизациясенең тулаем дөнья культурасы үсешендәге тарихи ролен ачып бирә. Экспозиция дүрт бүлектән тора.





«Борынгы Болгарны ачу» бүлегендә Болгар турында көнчыгыш, борынгы рус һәм урта гасыр Европа әсәрләрендәге мәгълүмат, шулай ук XIX-XX гасыр башында, совет чорында һәм хәзерге заманда Болгарның мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау тарихы турында мәгълүмат тупланган. «Болгар цивилизациясенең башлангычы һәм үсеше» бүлеге Идел буе болгарларының килеп чыгышы, аларның Кытайдан алып Көнбатыш Европага кадәр географик киңлектә тоткан урыны һәм роле турында сөйли. «Борынгы Болгар» бүлеге Болгарны урта гасыр ислам шәһәр культурасы үрнәге буларак тәкъдим итә: аның ныгытмаларын, архитектурасын, төзеклеген, һөнәрчелеген, сәүдә итү рәвешен, халыкара элемтәләрен, шулай ук халкының антропологиясен күрсәтә. «Болгарның табигате» бүлеге Болгар шәһәре тирәсендәге табигать шартлары турында мәгълүматтан торачак.

Инвестор:
«Татнефть» ААҖ.
Генераль директоры Шәфәгать Тәхаутдинов.

Подрядчы оешма:
«ПСО Казань» ҖЧҖ.
Генераль директоры Р.Х.Җиһаншин.









# Капитан коесы Сәхабәләргә һәйкәл







Болгар шәһәрлегенең төньяк-көнчыгыш өлешендә, Иерусалим чокыры тамагында Капитан коесы урнашкан. Аңа бу исем XVIII гасырда бу җирләрне өйрәнүче капитан Н.П.Рычков хөрмәтенә бирелгән. Татарлар чишмәне «Габдрахман сәхабә коесы» дип атыйлар һәм аның барлыкка килүен Болгар җиренә Мөхәммәт пәйгамбәр сәхабәләре килү белән бәйлиләр.

Риваять буенча, бу чишмәнең шифалы суы Габдрахман сәхабәнең юл таягы орынган урыннан ургып чыккан, әлеге су хан кызын савыктырырга булышкан. Кызының савыгу могҗизасын күреп, хан һәм аның иярченнәре ислам динен кабул иткән. Бу риваять Гренада сәүдәгәре, гарәп телендә сөйләшүче Хәмит Әл-Гарнати язмаларында тасвирланган вакыйгалар нигезендә туган. Хәмит Әл-Гарнати Идел буе Болгар дәүләтенә 1135 елда килгән, ул XI - XII гасырларда Болгар казые һәм тарихчысы булган Якуб ибне Ногман Әл-Болгариның китабын укыган.

Бу тарихи ядкәрнең тагын бер исеме – «Капитан коесы» рус сәяхәтчесе һәм географы Николай Рычков (1746-1784) исеменә бәйле. Ул Петербург фәннәр академиясенең Петр Симон Паллас җитәкчелек иткән экспедициясендә катнашкан. 1769 елда капитан Рычков кое янындагы территориядә тикшеренүләр алып барган. Биредә саз рудасы һәм порох ясау өчен кирәкле матдә - селитра табылган.

Комплекс территориясен реконструкцияләү һәм төзекләндерү «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе проекты буенча башкарылган.

Инвесторлар:
«Лукойл» ААҖ,
президенты В.Ю.Алекперов,

«Ритэк» ААҖ,
Директорлар советы рәисе В.И.Грайфер.





2012 елның 18 июнендә «Изге Болгар җыены» кысаларында сәхәбә җирләнгән урында сынчы һәм рәссам Рөстәм Габбасов проекты буенча эшләнгән истәлек билгесе ачылды. Истәлек билгесе өстенә арка корылган сигез почмаклы плитадан гыйбарәт. Терәкләрендә Мөхәммәт пәйгамбәрнең өч сәхабәсенең исемнәре татар, рус, инглиз һәм гарәп телләрендә язылган. Ә билгенең үзендә чалма, юл таягы һәм каурый каләмнең рельеф сурәте ясалган. Татар тарихчысы Хисаметдин ибне Шәрәфетдин Әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» китабында 681 елда Болгар тәхетенә Айдар хан утыруы турында риваять бирелгән. Аның буенча, Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең өч сәхабәсен – Габдрахман ибне Зөбәерне, Тальха ибне Госманны, Зөбәер ибне Җәгъдәне табиблар сыйфатында Болгарга җибәргән. Зөбәер ибне Җәгъдә пәйгамбәр биргән юл таягына таянып бу җирдә тәүге тапкыр вәгазь укыган. Унике елдан соң ике сәхабә Мәдинәгә кире кайткан, ә Җәгъдә исә хан кызы Туйбикәгә өйләнеп Болгарда калган. Риваятьтә язылганча, ул соңыннан Ханнар төрбәсе төзелгән урында җирләнгән.

Инвестор:
ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының башкарма директоры Тәлгать Абдуллин.

# Чатырлар лагеры Фестиваль-вакыйгалар комплексы








Чатырлар лагеры Болгар шәһәрлегенең үзәк өлешендә урнашкан. Хәрәкәтчән корылмалардан – палаткалардан, зур чатырлардан, стационар рәвештә куелган гомуми кулланылыш биналарыннан гыйбарәт. Инвесторы – НПО «Татэлектромаш» ААҖ (генераль директоры Илдус Исламов). Чатырлар лагеры җәй вакытында зыярәт кылучыларны, Болгарны карарга килүчеләрне һәм туристларны урнаштыру максатында төзелгән.

Чатырлар лагеры 2011 елда сафка бастырылды. Җәй саен биредә «Изге Болгар җыенында» катнашучылар, җәй көне археология практикасын үтүче студентлар яши. Лагерь төрле фестивальләрдә, слетларда катнашучыларны кабул итә. Мәсәлән, 2011 елда биредә Беренче республика балалар тарихи фестивалендә катнашучылар яшәде. 2012 елда чатырлар лагеренда «Сәләт» яшьләр форумы чаралары уздырылды.

---

Инвестор:
НПО «Татэлектромаш» ААҖ.
Генераль директоры Илдус Исламов.







Спас районының фестиваль-вакыйгалар комплексы Икмәк музее янында, Болгар шәһәрлегенең көньяк чиге артында урнашкан. Бу – хәрәкәтчән, җыелма конструкция. Аның эчендә 500 урынлык тамаша залы бар. Комплекс массакүләм тамаша чаралары – концертлар, спектакльләр, иҗат очрашулары һәм башкаларны үткәрүгә җайлаштырылган.









# Инфраструктура








Болгар шәһәрлеге территориясе буенча каты асфальттан берничә километр автомобиль юлы салынды, ул шәһәрлекне төньяк-көньяк, көнбатыш-көнчыгыш юнәлешләр буенча кисеп уза. Архитектура истәлекләре арасында җәяүлеләр өчен юллар, Иерусалим чокыры аркылы җәяүлеләр күпере салынды, Истәлек билгесе һәм Ак мәчет янындагы территорияләр төзекләндерелде.

Кече манара һәм Ханнар төрбәсе, Кара пулат, Габдрахман коесы, Ак мәчет, Икмәк музее янында агачлар утыртылды.

Инвесторлар: газ:
«Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ.
Генераль директоры Р.А.Кантюков,

электр: «Татэнерго» ААҖ.
Генераль директоры И.Х.Гайфуллин.



Болгар шәһәрлегенең көнбатыш, көнчыгыш һәм көньяк керү юлларында капка-манаралар яңадан төзелде.

Инвесторлар:
«СМП –Нефтегаз» ААҖ
нең хуҗалары – аталы-уллы Ф.Ф.Комаров
һәм Р.Ф.Комаров.





# *Зөя утравы*



# Тарихи белешмә







Зөя (Свияга) һәм Идел елгалары кушылган урын - балыклы күлләргә, күпсанлы култыкларга бай җирләр борынгыдан ук кеше игътибарын җәлеп иткән. Археология табылдыклары бу җирләргә кешеләрнең безнең эрага кадәр 4-6 меңенче елларда ук актив рәвештә урнаша башлауларын раслап тора. Соңрак бу җирләргә фин-угыр ыруглары күчеп килгән, ә Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында алар әлеге дәүләтләр кул астындагы территорияләргә кергәннәр. Иделнең биек уң як ярындагы бу Түгәрәк тау ул заманнарда тугайлар арасында куе урман белән капланган калкулык булган, елъязма чыганакларына караганда, анда мәҗүси чирмеш ыругларының изге агачлыгы булган.

Свияжскиның - Зөя шәһәренең төзелү тарихы гаҗәеп: 1550 елның кышында бу Түгәрәк таудан 800 чакырым ераклыкта, Углич янындагы ерак урманда диварлары, манаралары, чиркәүләре һәм торак йортлары булган шәһәр бурап куелган, ә 1551 елның язында, бураларны, сүтелгән килеш, Зөя елгасы тамагына агызып китергәннәр. Бары тик дүрт атна эчендә дьяк Иван Выродков җитәкчелегендә Мәскәү патшалыгының иң зур кальгасы калкып чыккан, ул, үлчәмнәре буенча, шул замандагы Мәскәү, Псков яки Новгород кальгаларыннан зуррак булган. 1552 елда, Казан буйсындырылгач, Зөя шәһәре кыска гына вакыт яулап алынган төбәкнең хакимият үзәге ролен үтәгән. Соңыннан Иделнең уң як ярындагы кушылган җирләргә күзәтчелек иткән. XVI-XVIII гасырлардагы күпсанлы сугышларда катнашучы яугирләр сугышка биредән киткәннәр, шушы җиргә үк - бик ерактагы Успение монастырена дәүләт җинаятьчеләрен һәм патша җәзасына эләгүчеләрне сөргәннәр. Зөя шәһәре иң югары икътисадый үсешкә XVII-XVIII гасырларда – аның аркылы зур сәүдә юллары үткән чорда ирешкән. Губерния реформасы үткәрелгәннән соң Зөя шәһәре бай Казан губерниясенең өяз үзәге булган.

Борын заманнардан ук ул үзенең храмнары һәм монастырьлары белән дан тоткан. XVI гасырда нигез салынган Успение ирләр монастыре ансамбле, XIX гасырда Иоанн Предтеча хатын-кызлар монастыре монахиняләры урнашкан Троица монастыре һәм XX гасыр башы давылларында исән калган бердәнбер приход чиркәве – Константин һәм Елена чиркәве безнең көннәргә кадәр сакланып калганнар. Зөя утравында урта гасыр шәһәренең бай тарихы уникаль юеш археология катламы булу нәтиҗәсендә сакланып калган. Бу катлам 1956 елда Куйбышев сусаклагычы төзегәннән соң фомалашкан.

XX гасырның иң фаҗигале вакыйгаларын – Беренче бөтендөнья сугышын, утрауның үзендә гөрселдәгән Гражданнар сугышын, утрауның зур өлешен репрессияләр ясау учреждениеләре басып алган сәяси репрессияләр чорын, Зөя утравының берничә йөз кешесе башын салган Бөек Ватан сугышын, СССР таркалгандагы болганчык елларны Зөя шәһәре бөтен ил белән бергәләп кичергән. Башка бөтен җирдәге кебек үк, сәяси хәлләр биредә дә кеше язмышлары сынуына, икътисадның артта калуына, тарихның һәм мәдәниятнең гүзәл истәлекләренең җимерелүенә китергән.

Бәхеткә, «Яңарыш» фонды оештырылу нәтиҗәсендә Зөя утравы бүген яңадан туа - архитектура истәлекләре реставрацияләнә, храмнарда гыйбадәт кылу кабат башланды, туристлык үсү аркасында утрауның икътисады җанлана. Ул бүген борынгы Болгар белән беррәттән рухиятнең һәм күпмилләтле халкыбызның тирән әхлакый мөмкинлегенең яңарышы символы булып тора.








# Успение монастыре









Биредәге Богородица-Успение ирләр монастырена Зөя шәһәренең үзе белән бер үк вакытта нигез салынган. Аңа яулап алган җирләрдәге халыкларны православиегә диненә тарту бурычын үтәргә тиешле миссионерлык үзәге вазыйфасы йөкләнгән, шуңа күрә Явыз Иван бирегә ул чорның иң оста төзүчеләреннән Псков осталары Постник Яковлевны һәм Иван Ширяйны җибәргән. Алар Мәскәүнең Кызыл мәйданында әлегәчә Россия символларының берсе булып торучы Покров соборын, (аны әле Василий Блаженный соборы дип тә атыйлар) төзеп мәңгелек дан казанганнар. Зөя утравындагы Никола чиркәвен, Успение соборын шушы осталар төзегән. Бу храмнар бик озак вакыт Зөя шәһәренең агач крепостенда бердәнбер таш корылмалар булганнар. Соңрак, XVIII-XX гасырларда монастырьның территориясе киңәю сәбәпле, башка корылмалары да барлыкка килгән. Совет хакимияте елларында монастырь комплексында - ИТК-5 (Төзәтү-хезмәт колониясе), аннан соң Республика психоневрология диспансерының филиалы урнашкан. 1980 нче еллар ахырында храмнар дин тотучыларга кайтарылган.





# Успение соборы









Успение соборы – Зөя утравының энҗе бөртеге, ул 1556 елда төзелгән.

XVIII гасырда өлешчә үзгәртеп корылган (трапезная, барабан, фасадлар, тәрәзә уемнары бизәлеше), бу соборның тышкы күренешенә барокко төсмере керткән. Эчке өлешендә XVI гасыр ахырына караган уникаль фрескалар җыелмасы сакланып калган, шул исәптән иконография буенча бик сирәк очрый торган фреска - изге Христофор сурәте.

Храмны реставрацияләү буенча эшләр фрескаларны нығыту һәм саклау буенча күпьеллык хезмәтне дәвам итүне үз эченә ала. 2011-2012 елларда храмның идән асты чүптән чистартылды, храмның нигезе ныгытылды һәм гидроизоляцияләнде, бу исә храмга зыян китерүче җир асты суларыннан арынырга мөмкинлек бирде. Шулай ук бакыр түбә алмаштырылды, храмнарның фасадларын реставрацияләү буенча күләмле эшләр башкарылды.

Инвесторы - Казан вертолет заводы. Реставрация төгәлләнгәннән соң храмны дин тотучыларга кайтару күздә тотыла, әмма ул туристлар өчен дә реставрацияләүче белгечләр өчен дә ачык булырга тиеш.

Фасадларда реставрация эшләре башкарылды: акташ һәм кирпеч тезмәләрне төзәтү, диварларны сылау, диварларны махсус реставрацион составлар кулланып буяу, тәреләрне ясату, алтын йөгертү һәм храм өстенә урнаштыру, түбәләрне төзекләндерү. Соборның аскы катында, ачык болдырында (паперть) реставрация эшләре: җимерелгән өлешләрне яңадан тезү, гидроизоляция, антисептика ясау, өслекләргә гидрофобизация ясау, ак таштан идән җәю.

Собор интерьерларында реставрация эшләре: ак таштан идәннәр түшәү, үзәк өлештәге рәсемнәрне реставрацияләү.

Территорияне төзекләндерү, сукмакларга, юлларга, мәйданчыкларга дискретлы катлам җәю.

Инвестор:
«Казан вертолет заводы» ААҖ.
Генераль директоры В.А.Лигай.









# Никола Чудотворецка багышланган чиркәү





Зөя утравындагы иң борынгы урта гасыр чиркәүләренең берсе булып тора. Никола Чудотворец чиркәве Идел буенда чукындыру йоласы башкарыла торган беренче таш храм. Аңа 1955 елда нигез салынган һәм аны 1556 елның 6 декабрендә архимандрит Герман изгеләндергән. Ташчы оста Иван Ширяй һәм архитектор Постник Яковлев (Барма) җитәкчелегендәге Псков осталары артеле төзегән. Чиркәүнең эчке диварларына фрескалар ясалган булган, көнчыгыш фасадтагы Никола Можайский сурәте фрагментыннан башка берсе дә безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Монда изге Германның борынгы хөҗрәсе (келья) сакланган. Изге Герман мәетеннән калган әгъзалар (мощи) 1922 елга кадәр биредәге Успение соборында кадерләп сакланган. Чиркәүгә XVII гасырда 43 метр биеклектәге дүрт катлы чиркәү манарасы тоташтырып төзелгән.

2010-2012 елларда реставрация барышында түбәндге эшләр башкарылган: нигезләрне ныгыту һәм гидроизоляция үткәрү, фасадларны реставрацияләү, түбә конструкцияләрен төзәтү, түбәгә бакыр япманы һәм чирәү манарасына главкаларны урнаштыру, су агу системасын кую, гөмбәзне өлешчә чистарту, гөмбәздәге һәм диварлардагы ярыкларны сылау, тәрәзәләрне төзәтү, тәрене реставрацияләү, баскычны реставрацияләү, храмның төньяк янкормасы өчен главка белән барабанны яңадан ясау.



2013-2014 елларда эчке реставрация һәм XVI гасыр борынгы рус фрескаларының сакланып калган өлешләрен консервацияләү, җуелган иконостасны яңадан ясау, инженерлык челтәрләрен кору эшләренә тотыну, чиркәү янындагы территорияне төзекләндерүне төгәлләү планлаштырыла.

Реставрация тәмамланганнан соң храмны дин тотучыларга бирү күздә тотыла.

Инвестор:
«Концерн «Радиоэлектронные технологии» ААҖ.
Генераль директоры Н.А.Колесов.









# Туганнар корпусы







Туганнар корпуслары, исеменнән күренгәнчә, монастырьдагы ир-ат монахлар (братья) өчен яшәү урыны. Башта агачтан, XVII гасырдан башлап таштан төзелгәннәр һәм XX гасыр башына кадәр киңәя барганнар. XIX гасырда корпусларга тоташтырып изге Гурий һәм Митрофан Воронежскийга багышланган чиркәү төзелгән. 1930 нчы елларда храм өлешчә сүтелгән. Сугышка кадәрге чорда - 1931 елдан 1938 елга кадәр биредә - ГУЛАГ (ИТК-5), XX гасырның 1940-1990 елларында - психиатрия хастаханәсе урнашкан. 1997 елда Богородица-Успение ирләр монастыре яңадан эшли башлаган.

Успение монастыре комплекслары корылмалары арасында Туганнар корпусы вакытлар узудан иң зур зыян күргән бина, атап әйткәндә XX гасырның 90 нчы елларында ясалган уңышсыз «реставрация» аркасында бина тулысынча җимерек хәлгә килгән, аннан тышкы һәм өлешчә эчке диварлар гына сакланып калган. Инвестор – «КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан реставрация һәм





тарихи кыйммәте булган барлык элементларны саклаган хәлдә, бинаның юкка чыккан конструкцияләрен яңадан төзү буенча гаять зур күләмдә эш башкарылды: бинаның нигезләре һәм сакланып калган диварлары ныгытылды, диварларның һәм гөмбәзләрнең авария хәлендәге өлешләре яңадан төзелде, түшәмнәр, түбәләр һәм рундук болдырлар эшләнде. Барлык коммуникацияләр – җылыту, су белән тәэмин итү, канализация һ.б. системалары тулысынча эшләнде. Корпус тирәсендәге территория тулысынча төзекләндерелде. Изге Герман хөрмәтенә главкалы һәм тәреле храм торгызылды.

Хәзерге вакытта корпуста Изге Герман чиркәве эшли, әлеге бина шулай ук монастырьның идарәсе һәм кунакханәсе (трапезная, кухня) сыйфатында файдаланыла.

---

Инвестор:
«КамАЗ» ААҖ.
Генераль директоры С.А.Когогин.









# Архимандрит корпусы







XVII гасырда төзелгән бу ике катлы бинага Архимандрит корпусы дигән исем XIX гасырның икенче яртысында - аны Успение монастыреның архимандриты резиденциясе сыйфатында файдалана башлагач бирелгән. Моңа кадәр ул монастырь училищесының уку бинасы булган. Совет чорында бинага бик нык зыян килмәгән, чөнки ул заманнарда биредә монастырь территориясендә эшчәнлек итүче учреждениеләрнең идарәсе урнашкан. XX гасырның 30 нчы елларында бина төрмә хакимияте карамагында булган, соңрак Свияжск психиатрия хастаханәсенең дәвалау палаталары буларак файдаланылган.

Комплексы төзәтү-реставрация һәм торгызу эшләре барышында диварлардагы һәм гөмбәзләрдәге ярыклар сыланды, фасадларга реставрация ясалды, кызыл болдыр яңадан төзелде, такта түбә, мич торбалары, тәрәзәләр һәм ишекләр куелды, агачтан һәм ак таштан идәннәр түшәлде, мебель һәм кухня җиһазлары урнаштырылды, әйләнә тирәсе чистартылды, төзекләндерелде. Бинага барлык коммуникацияләр дә кертелде.

Архимандрит корпусы 2011 елда кулланууга тапшырылды. Ул монах хөҗрәләре һәм монастырь башлыгының бүлмәсе итеп җайлаштырылды.





---

Инвестор:
Татарстан Республикасы Төзелеш һәм архитектура буенча ведомстводан тыш дәүләт экспертизасы идарәсе,
идарә җитәкчесе В.С.Маркелов.









# Монастырь училищесы







Монастырь училищесының матур, ике катлы, зур булмаган бинасында (XVII-XIX гасырлар) монастырь училищесы үзе һәм нота белеме мәктәбе урнашкан. Биредә бөтен Зөя өязеннән балалар һәм яшүсмерләр укыган.

Реставрация барышында бинаның нигезе ныгытылды һәм аңа гидроизоляция ясалды, диварлар ныгытылды, ярыклар сыланды, агач идәннәр түшәлде, фасадларга реставрация ясалды, тәрзә уемнары яңадан эшләнде, тәрәзәләргә һәм ишекләргә агач блоклар куелды, агач түбә куелды, бинаның эчке өлеше бизәлде, тирәсендәге территория төзекләндерелде. Бина барлык коммуникацияләр белән тәэмин ителде.



Монастырь училищесы 2011 елда сафка басты, ул хәзер монастырьның хөҗрәләре сыйфатында файдаланыла.

Инвестор:
«Нәфис косметикс» ААҖ.
Генераль директоры Д.В.Хәйбуллин.






# Вознесения Господня чиркәве һәм койма







Капка өстендә урнашкан Вознесение чиркәве бинасы (XVIII-XIX гасырлар) узган гасырның 20-30 елларында беренче кат дәрәҗәсенә кадәр җимерелгән. Капка уемында тышкы фреска сурәтләрнең эзләре сакланып калган. Бәхеткә каршы, сакланып калган күпсанлы тарихи фотографияләр һәм сызымнар аның иң баштагы тышкы күренешен дөрес итеп яңадан төзергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Төзелеш һәм архитектура буенча ведомстводан тыш дәүләт экспертизасы идарәсе фәнни реставрация проекты буенча биредә чиркәүнең XVIII гасырдагы күренешен яңадан торгызу буенча эш алып бара. Бүгенге көнгә храмның беренче каты буенча эшләр башкарылды: нигезләре һәм диварлары ныгытылды, диварларның һәм гөмбәзләрнең авария хәлендәге өлешләре яңадан тезелде, ярыклар сыланды, диварларның кирпеч тезмәсен һәм фасадларның бизәлеш элементларын реставрацияләү буенча эшләр алып барыла. Фрескалар өлешчә консервацияләнде.

Монастырының таш коймасы XVIII-XX гасырларга карый. Башта ул Туганнар корпусыннан соң ук, зиратны урап, Успение соборының алтаре артыннан узган.





XIX гасыр ахырында, монастырь территориясе шактый зурайгач, койма да киңәйтелгән.

Монастырь диварлары моңарчы авария хәлендә иде. Диварларның көнбатыш өлеше яртылаш җиргә күмелгән, тезмәсе җимерелгән, биологик яктан зур зыян күргән. Реставрация барышында аерым өлешләренең нигезләре ныгытылды, авария хәлендәге өлешләре яңадан тезелде, каморларның аскы рәтендәге бойницалар (ату өчен тишекләр), диварлар периметры буйлап монастырь капкасы торгызылды. Койма төзәтелде, сыланды һәм буялды, сукмакларга дискрет катламлы ак таш җәелде. Успение урамында агач капка куелды.

Инвесторлар:
«ХК «Ак барс» ААҖ.
Генераль директоры И.М.Егоров.

Татарстан Республикасы Төзелеш һәм архитектура буенча ведомстводан тыш дәүләт экспертизасы идарәсе,
идарә җитәкчесе В.С.Маркелов.










# Иоанн Предтеча монастыре





Зөя утравындагы Иоанн Предтеча монастыре Рус православие чиркәве Казан епархиясенең борынгы монастыре. Революциягә кадәр хатын-кызлар монастыре булган, хәзерге вакытта - Успение ирләр монастыре йорты.

XVI гасырда нигез салынган (төгәл вакыты билгесез).

Монастырьның иң күркәм чоры - XX гасыр башы. Анда 400 гә якын монахиня һәм монахиня булырга хәзерләнүче исәпләнгән. Ул епархиядә, зурлыгы буенча, Казандагы Богородица монастыреннан соң икенче хатын-кызлар монастыре булып саналган.



Монастырь 1919 елда ябылган. Совет чорында барлык храмнар Зөя тарихи-архитектура музей-тыюлыгы карамагында булганнар. Хәзерге вакытта 3 храмның 2 се (Троица чиркәвеннән башка) Успение монастырена бирелде.


Монастырьның архитектура ансамбле:

- Троица агач чиркәве;
- Сергий таш чиркәве;
- Барлык Кайгыручылар Шатлыгы соборы.



# Троица чиркәве









Троица чиркәве - Урта Идел буенда сакланып калган бердәнбер иң борынгы агач корылма, 1551 елның май аенда бары тик бер көн эчендә төзелгән. Ул Зөя утравындагы бөтен комплексның иң уникаль объктларыннан берсе булып тора. XIX гасыр башында аны, реставрация турында шул чор күзаллаулары буенча, черүдән саклау өчен, такта белән тышлаганнар, бу аның күренешен шактый бозып торган. Революциядән соң ук ул дәүләт саклавы астына алынган һәм шул вакыттан алып музей объекты сыйфатында торган. 2010-2011 елларда Мәскәүдәге «Спецпроектреставрация» тарих һәм мәдәният истәлекләрен реставрацияләү буенча институтының баш архитекторы Б.Д.Лурье фәнни



җитәкчелегендәге реставрация барышында Троица чиркәвенең тышкы күренеше XVI гасыр храмнарына хас борынгы хәленә кайтарылды. Хәзерге вакытта XVIII гасыр агач иконостасын реставрацияләү буенча эшләр бара.

Реставрация тәмамланганнан соң чиркәү, белгечләрнең даими күзәтчелегенә мохтаҗ уникаль истәлек буларак, музей сыйфатында файдаланылачак, анда престол бәйрәмнәрендә гыйбадәт кылу да уздырачаклар.

---

Инвестор:
«Акульчев» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.
Идарәчесе С.Н.Акульчев.







# Барлык Кайгыручылар Шатлыгы соборы









Төзелү вакыты буенча бу собор иң соңгысы (1896-1906), ул уңышлы архитектура алымы кулланып яңа Византия стилендә төзелүе нәтиҗәсендә Зөя утравы символларының берсе булып тора. Архитектор Ф.Малиновский проекты буенча Изге Ананың Зөя утравында сакланган «Барлык Кайгыручылар Шатлыгы» могҗизалы иконасына багышлап төзелгән. Беренче Бөтендөнья сугышына кадәрге чорда храмны шактый югары дәрәҗәдәге академик рәсем сәнгате традицияләрендә, майлы буяулар белән ясалган рәсемнәр бизәп торган. Безнең көннәргә кадәр ниндидер могҗиза белән төп престолның 4 катлы, кысалы оригиналь иконостасы сакланган. Ул игуменья Апфия вакытында куелган булган. Ләкин кырыйдагы янкормаларның иконостаслары сакланмаган.

Реставрация барышында бик күп эшләр башкарылды: храм нигезенә горизонталь гидроизоляция ясалды, фасадлары һәм түбәсе төзәтелде, уелма бүрәнкәләр ясалды, тәрәзәләргә һәм ишекләргә яңадан ясалган һәм реставрацияләнгән агач блоклар урнаштырылды. Храмда ел әйләнәсе гыйбадәт кылу мөмкинлеген тәэмин итү өчен яңа куелган газ казаннары храмны җылыту өчен тарихи калориферлы системадан файдалана.






# Барлык Кайгыручылар Шатлыгы соборы









Храмда кирәкле барлык инженерлык системалары булдырылган. Чүкеп ясалган ишекләр һәм тәрәзә рәшәткәләре реставрацияләнде, алтын йөгертелгән тәреләр ясалды. Территорияне төзекләндерү эшләре: дискрет катламлы юллар һәм мәйданчыклар салынды. Үзәк иконостасны реставрацияләү буенча эш төгәлләнде, иконостасның кырыйларындагы янкормаларның өч катлы иконостасларын яңадан төзү, храмның эчке бизәлешен һәм майлы буяу белән ясалган рәсемнәрен реставрацияләү буенча эш бара. Реставрация тәмамланганнан соң храмны дин тотучыларга бирү күздә тотыла.

Инвесторлар:
«Сбербанк России» ААҖ.
Президенты һәм идарә рәисе Г.О.Греф.

«Россия тимер юллары» ААҖ.
Президенты В.И.Якунин.

Россиянең танылган эшмәкәрләре
Г.Тимченко һәм А.Р.Бокарев.



# Сергий чиркәве









Сергий чиркәве (1570-1604 еллар) Борис Годунов заманында ук, биредә аталы Троица –Сергий лаврасының йорты – Троица монастыре булган чорда ак таштан төзелгән. Ул Зөя утравының яклаучысы булып саналган Сергий Радонежскийга багышланган. Үз эченә храмны, трапезная бүлмәсен һәм хуҗалык биналарын алган әлеге храмның төзелеше гаять кызыклы. Чиркәү ишеге янында «Троица Ветхозаветная» дигән борынгы фреска һәм храмны изгеләндерү вакыты күрсәтелгән язма сакланып калган.

Реставрация барышында храмның нигезе ныгытылды һәм гидроизоляцияләнде, диварлар, гөмбәзләр реставрацияләнде: ак таш, кирпеч тезмәләр төзәтелде, ярыклар сыланды һәм буялды.

Храм гөмбәзләренең тышкы өслегендәге махсус япма-түбә яңадан эшләнде, четверик һәм трапезная түбәләре реставрацияләнде, өсләре бакыр белән капланды, главалар һәм гөмбәз түбәләре дә бакыр белән капланды. Алтын йөгертелгән тәреләр эшләнде һәм храм, чиркәү манарасы, янкорма чиркәү өсләренә куелды. Чүкеп ясалган ишекләр реставрацияләнде, тәрәзә капкачлары эшләнде.

Храмның интерьерын реставрацияләү буенча эш бара. 2013 елда борынгы фресканы консервацияләү, вертикаль планировка ясау һәм храм тирәсендәге территорияне төзекләндерү планлаштырыла. Җуелган иконостасларны 2014 елда яңадан ясау күздә тотыла.

Реставрация тәмамланганнан соң храм дин тотучыларга биреләчәк.











Инвестор:
«Банк Зенит» ААҖ.
Директорлар советы рәисе А.А.Соколов.

# Иоанн Предтеча монастыреның коймасы













Иоанн Предтеча монастыреның коймасы XIX-XX гасырларда төзелгән. Аның почмак өлешендә җеназа уку өчен зур булмаган часовня урнашкан, гөмбәз түшәмендә һәм диварларга майлы буяу белән ясалган сурәтләр яхшы сакланган.

Часовняда уздырылган реставрация эшләре нигезне һәм диварларны ныгытуны, диварның авария хәлендәге өлешләрен яңадан тезүне, түбә системасын төзәтүне, түбә алмаштыруны үз эченә алды. Интерьерлар реставрацияләнә, иделәр алмаштырылды, коммуникацияләр үткәрелде һәм чүкеп ясалган тәрегә алтын йөгертелде. Тирәсендәге территория чистартыла-төзекләндерелә.



Часовня интерьерларындагы рәсемнәрне торгызу көздә тотыла.

Монастырьның авария хәлендәге диварын реставрацияләү барышында аның кыйшайган урыннарын тигезләү, диварларның тарихи тезмәләрен саклаган хәлдә нигезләрен ныгыту буенча гаять катлаулы эш башкарылды. Койма төзәтелде, сыланды һәм буялды. Почмактагы манарлар реставрацияләнде, тарихи-архив һәм библиография материаллары буенча монастырь комплексының капкасы яңадан төзелде. Капка каравыллаучы хатын-кызларның диварга сөялеп торган хөҗрәләре шулай ук реставрацияләнде, территориия төзекләндерелде, дискрет катламлы ак таштан сукмаклар ясалды.









# Иоанн Предтеча монастыренең Туганнар корпуслары







Иоанн Предтеча монастыреның Туганнар корпусларында (XIX гасыр ахыры -XX гасыр башы) әлеге монастырьның күпсанлы монахинялары, монахиня булырга хәзерләнүче хатын-кызлар яшәгән. Бу биналар ул заманнардагы монастырь торакларының кызыклы үрнәгеннән гыйбарәт. Совет чорында бу корпуслар Зөя утравында авария хәлендәге һәм тузган торакны бетерү программасы барышында күченүчеләр өчен коммуналь фатирлар сыйфатында файдаланылганнар.





Хәзерге вакытта монда реставрация эшләре бара, алар тәмамлангач, бу биналарда бирегә зыярәт кылырга килүчеләр өчен кунакханә оештырылачак.

Инвестор:
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәхләт торак фонды, башкарма директоры Тәлгать Абдуллин.











# Константин һәм Елена чиркәве









Константин һәм Елена чиркәве XVII гасырда төзелеп Зөя утравында безнең көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер приход чиркәве булып тора. Авторы билгесез. XVI гасырда, Явыз Иван патша кушуы буенча төзелгән агач чиркәү урынына, кирпечтән салынган. Бу - борынгы рус таш төзелеш сәнгате традицияләрендә, барокко элементларын файдаланып төзелгән гыйбадәт архитектурасы истәлеге.

Фаразларның берсе буенча, чиркәүне Константин һәм Елена патшалар хөрмәтенә атауның сәбәбе Явыз Иван гаскәрләренең Зөя утравына изге Константин һәм Елена истәлеге көнендә килеп төшүендә булырга мөмкин. Өстәвенә, Явыз Иван Елена патшабикә улы булган.

Константин һәм Елена чиркәвенең беренче өлкән побы – Зөя утравындагы Изге Ана Успение ирләр монастырена нигез салучы Герман атакай.

1939 елда иерей Анатолий Романовский чиркәүдә соңгы тапкыр гыйбадәт кылган һәм чиркәү ябылган. Узган гасырның 80-90 елларында храм музей бүлеге буларак файдаланылган, чөнки аны ТАССР ның Дәүләт музееe карамагына тапшырганнар. 1993 елда храм яңадан дин тотучыларга кайтарылган. Гыйбадәт кылу өчен Константин һәм Елена хөрмәтенә престол яңартылган.

2010 елда «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм утрау-шәһәр Свияжск» комплексы проекты кысаларында храмда реставрация эшләре башланды.






Реставрация барышында хармның нигезе ныгытылды һәм аңа гидроизоляция ясалды, фасадларны һәм түбәне төзәтү, эчке ягын бизәү эшләре үткәрелде, тәреләргә реставрация ясалды һәм алтын йөгертелде, агач эшләнмәләр ясалды һәм урнаштырылды, храмның төньяк янкормасы торгызылды, анда чукындыру йоласын үтәү өчен купель куелды. Приход чиркәвенең югалган часовнясы һәм капкалы коймасы торгызылды. Храмга кирәкле бөтен инженер системалары куелды.

Константин һәм Елена чиркәвенең манарасында 1939 елдан бирле чаңнар булмаган. 2012 елның 16 июнендә чиркәү манарасына алты чаңнан торган звонница куелды. Йөз еллап вакыт узганнан соң храм яңадан чаңлы булды. Чаң-кыңгыраулар бронзадан (80% ы бакыр һәм 20 % ы кургаш) Мәскәүнең ЛИТЭКС заводында коелды. Аларның авырлыгы - 4 кг нан 80 кг га кадәр, диаметрлары – 200 мм дан 478 мм га кадәр. Кече звонница кечкенә диаметрлы - өч, зур диаметрлы өч кыңгыраудан тора. Алар гармонияле рәвештә сайланган киң музыкаль диапазонлы каноник авазлар рәтен тәшкил итә.

---

Инвесторлар:
«Лукойл» ААҖ.
Президенты В.Ю.Алекперов,

«РИТЭК» ААҖ.
Директорлар советы рәисе В.И.Грайфер.







# Казна корылмалары биналары комплексы (Зөя утравы музее)







XIX гасырда типовой проект буенча төзелгән бу комплекс гражданлык төзелеш сәнгатенең бик яхшы сакланган үрнәге булып тора. Төзелгәннән соң анда казна контоpалары, казначейство урнашкан, ишегалдындагы өч бинада төрмә булган. Совет чорында исә биналарның дүртесен дә НКВД төрмәсе иткәннәр. Россиянең һәм Татарстанның бик күп күренекле мәдәният эшлеклеләре шушы төрмә аркылы узган. Төрмә ябылгач, 2000 нче еллар башына кадәр бу биналарда республика коррекцион мәктәп-интернат эшләгән. XX гасыр буена бер тапкыр да капиталь ремонт үткәрелмәү сәбәпле бу биналар реставрация алдыннан бик начар хәлдә иде. Инвесторның тырышлыгы нәтиҗәсендә биналар норматив дәрәҗәгә китерелде, газ белән җылыту системасы кертелде, бина конструкцияләренең барлык элементлары буенча гаять зур күләмдә эш башкарылды.





Хәзерге вакытта монда Зөя утравы тарихы музее - «Свияжск утрау шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» эшли, музейның даими экспозициясен оештыру эше бара, Зөя утравы тарихына багышланган күргәзмәләр үткәрелә. Күргәзмәләрдән тыш кызыклы очрашулар, фестивальләр, театр һәм музыка коллективлары чыгышлары, концертлар оештырыла. Туристларны һәм Зөя утравында яшәүчеләрне традиция буенча Свияжская Масленица дигән халык бәйрәме җәлеп итә: коймаклар пешерелә, самавырдан чәй эчәргә һәм халык уен-көлкесендә катнашырга мөмкин.

Инвестор:
«ТАИФ» ААҖ.
Генераль директоры А.К.Шиһабетдинов.









# Инженер корпусы казармасының ике катлы бинасы









Инженер корпусы казармалары XX гасыр башында Зөя утравы мәйданнарының берсендә, Идел аша Романов тимер юл күпере төзү белән бер үк вакытта барлыкка килгән. Ике катлы бинада идарә бүлмәләре урнашкан, бер катлы бина торак корпусы ролен үтәгән. Совет чорында ике катлы бинада авыл клубы эшләгән, китапханәсе һәм кино күрсәтү җайланмасы булган. XX гасыр ахырындагы янгыннан соң бинаның диварлары гына торап калган.

Бинага реставрация ясалды һәм «Свияжск утрау шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» ның фондларын саклау бинасы сыйфатында кулланугa җайлаштырылды, тиешле инженер системалары белән җиһазландырылды.



Инвестор:
«Казан моторлар төзү берләшмәсе»» ААҖ.
Генераль директоры Д.З.Кәримуллин.






# Инженер корпусы казармасының бер катлы бинасы









Инженер корпусы казармасының бер катлы бинасы XX гасыр башында төзелгән. Совет чорында интернат-мәктәп каршында урнашкан бу бина клуб сыйфатында файдаланылган. Реставрация барышында түбә ясау һәм төзекләндерү-реставрация эшләре башкарылды, кирәкле инженер системалары ясалды, бина «Свияжск утрау шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее»ның конференцияләр үзәге булы-



рак хезмәт итә. Биредә 60 һәм 12 урынлы ике зал бар, алар Зөя поселогының клубы ролен дә башкара.

---

Инвестор:
«С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация - җитештерү берләшмәсе» ААҖ.
Генераль директоры В.К.Каюмов.






# XX гасыр Җәмәгать бинасы













2011 елда Зөя гимназиясе бинасына тугәл 100 яшь тулды. Зөя утравы музеенда төрле елларда әлеге уку йортында укучыларның дәфтәрләре һәм альбомнары саклана. Шушы еллар эчендә бина уку учреждениесе вазыйфаларын үти. Биек калкулыкта, романтика, ялган готика стилендә төзелгән бу бина Зөя утравына су юлы буенча килүчеләрнең игътибарын үзенә тартып тора.



Бинада киң колачлы реставрация эшләрен үткәргәннән соң мәгариф үзәге урнашты. Анда ЮНЕСКО ассоциацияләшкән мәктәбе, һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бүлмә бар. Мәктәптә даими рәвештә мәдәни мирасны саклауга багышланган конференцияләр һәм семинарлар уздырыла.









# Богадельня







XIX гасыр ахырында төзелгән богадельня (гарипләр йорты) бинасы Зөя утравының безнең көннәргә кадәр иң яхшы сакланып калган урамында - Мәскәү урамында урнашкан. Революциядән соң, богадельня ябылгач, бинада берникадәр вакыт сукыр һәм начар күрүче балалар өчен мәктәпнең бер корпусы эшләп килгән. XX гасырның 80 нче елларыннан башлап бу бинада Татарстанның рәсем сәнгате музее филиалына караган «Свияга» кунакханәсе урнашкан.

Реставрация барышында инвестор тарафыннан бинаны кунакханә һәм Зөя утравы музееның кафесы итеп җайлаштыру өчен зур эш башкарылды. Кунакханәнең һәрбер бүлмәсенең



үз исеме бар: «Щука», «Лещь» һәм башкалар.

Алар Зөя елгасындагы гадәти балыклар хөрмәтенә шулай аталганнар. Реставрация барышында богадельня комплексының агач флигеле торгызылды. Анда да музей кунаклары өчен бүлмәләр, хуҗалык корылмалары: балалар белән дәресләр үткәрү өчен музей остаханәсе, мунча, җәмәгать бәдрәфе урнашкан.

Инвестор:
«Казанькомпрессормаш» ААҖ.
Генераль директоры И.Г.Хисамиев.






# Каменев йорты









Шәһәрнең элеккеге башлыгы һәм хәйрияче сәүдәгәр Каменев йорты XIX гасыр ахырында төзелгән, Утрауның төп мәйданында – Раштуа мәйданында урнашкан. Совет чорында бинада икмәк пешерү йорты һәм кибет эшләгән, биредә яңа пешкән икмәк һәм азык төлек сатканнар. Соңыннан бинаны торак иткәннәр. Кызганыч ки, 1990 еллар азагында бинаны ремонтлау һәм эшләтү өчен акча җитмәү сәбәпле, ул тулысынча диярлек җимерелгән.



«Бәхетле» компаниясе үткәргән комплекслы реставрациядән соң Каменев йортында шул исемдәге кунакханә ачылды, аның бүлмәләре бик уңайлы һәм зиннәтле, зур булмаган кафесы да бар.

Инвестор:
«Бәхетле» җаваплылыгы
чикләнгән җәмгыяте.
Генераль директоры М.Х.Латыйпова.






# Ат утары биналары комплексы









Успение монастыренең Ат утары комплексы – бу төрдәге гражданлык архитектурасының уникаль өлгесе. Күп очракта мондый ат утарлары комплекслары тулысынча юкка чыкканнар. Комплекс XVI гасырдагы агач утар урынына XVII-XVIII гасырларда кирпечтән төзелгән.

Реставрация барышында комплекска аның XX гасырда нык үзгәртелгән беренчел күренеше кайтарылды.

Ул заманда бирердә башта төзәтү-хезмәт колониясенең, аннан соң психиатрия хастаханәсенең хуҗалык хезмәтләре эшләгән.




Аның территориясендә һөнәрчеләрнең остаханәләре һәм кибетчекләре, «Трактир» кафесы, зур булмаган кунаханә, ат абзары, атлар чаптырыр өчен манеж урнашкан. Ат утары биналары комплексы - Зөя утравы музее белән беррәттән, бирегә килгән туристларның һәм кунакларның барысының да яраткан урыны.

Инвестор:
«Татспиртпром» ААҖ.
Генераль директоры Г.Ф.Куприянов.







**XVIII-XIX гасыр Өяз училищесы бинасы, XIX гасыр ахыры -XX гасыр башы чиркәү-приход мәктәбе бинасы, надворный советник Крылов йорты**

XVIII гасыр ахырында төзелгән, 1843 елда Петербург архитекторы Гартман проекты буенча үзгәртеп корылган. Бер катлы зур, кирпеч бина, планда квадрат рәвешендә, түбәсе дүрт кыеклы, бизәлеше юк диярлек. Мезонины җуелган. Төп фасады Троица урамына карап тора. Классицизм традицияләрендә төзелгән архитектура истәлеге.

1818 елдан анда Свияжск өяз һәм приход училищелары, соңрак – шәһәр училищесы, гимназиянең беренче сыйныфы урнашкан. 1920 нче еллар ахырында бу йортта Татарстанны өйрәнү җәмгыятенең Свияжск бүлеге күргәзмәсе урнашкан.

Аннан соң бина торак йортка әйләндерелгән. Хәзерге вакытта биредә беркем дә яшәми.

Комплексны проктны гамәлгә ашыру кысаларында тәзәтү-реставрация һәм торгызу эшләре башкарылачак, алар тәмамлангач, бинада Комплексны реставрация тикшерүләре үзәге эшләячәк.









**Земство хастаханәсе биналары комплексы**

XIX гасырның 70 нче елларында төзелгән. Бу бинага авырулар сукмагы өзелмәгән – җирле табибларның даны өяздән еракларга таралган. XX гасырның уртасына кадәр биредә бөтен Идел буеннан килгән авыруларны дәвалыйлар. Утрауда төрмә барлыкка килгәч, бирегә тоткыннарны да җибәрә башлаганнар. 50 нче елларда хастаханәне торак йортка әйләндергәннәр. Палаталар фатирларга әверелгән.

Хәзерге вакытта бу йортта яшәгән кешеләр күчерелгән. Комплексны проктны гамәлгә ашыру кысаларында заманча кулланылышка кертү максатында биредә төзекләндерү-реставрация эшләре алып барыла.












**Һөнәрчелек училищесы биналары һәм янгын обозы комплексы**

Зөя утравының үзәгендә, Раштуа мәйданында урнашкан, ике этапта төзелгән: 1870 елларда һәм XX гасыр башында. Архитектура стиле - классицистик юнәлештәге бизәлеш элементлары белән эклектика.

1892 елда комплексның ике катлы таш йортларының берсендә - шәһәр управасы һәм ирләр приход училищесы, ә 1900 елдан китапханә дә булган. Агач каланчалы күрше йорт янгын обозы хезмәткәрләре карамагында булган, алар анда хуҗалык әйберләре саклаганнар. 1880 елга янгын бинасы өстенә каланча төзеп куелган. Өченче бинада 1900 елда хатын-кызлар приход училищесы эшләгән.

1903 елда шәһәр идарәсе бинасына тоташтырып янгын обозы хезмәткәрләре өчен таш бина төзегәннәр. Бу бина өстенә икенче кат корылган, аны халыкның аеклыгын кайгыртучы попечительләрнең җирле комитетына лекцияләр һәм башка файдалы чаралар үткәрү өчен биреп торганнар. Янгын обозы бинасы ат абзары итеп үзгәртелгән, аңа ялгап солы саклау һәм хуҗалык хаҗәтләре өчен баз төзелгән.







Нәтиҗәдә 1908 елда комплекс ике катлы ике таш йорттан һәм агач каланчалы бинадан торган.

1910 нчы елларда комплекста түбән һөнәри мәктәп урнашкан.

Совет чорында монда интернат-мәктәп сыйныфлары булган.

Хәзерге вакытта бу бинада Зөя поселогының хакимияте һәм утрауның аерым хезмәтләре - полиция бүлегенең терәк пункты, фельдшерлык-акушерлык пункты, почта бүлеге, авыл китапханәсе һәм АТС эшли. Аларны башка бинага күчерү мәсьәләсе хәл ителә.

Һөнәрчелек училищесы һәм янгын обозы биналары комплексы нигезендә утрауда яшәүчеләр тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәймиев ярдәме белән Россиядә беренче булып онкология һәм башка каты авырулар кичергән балалар өчен «Островок» сәламәтләндерү үзәге булдырылачак.

Төзекләндерү-реставрация эшләрен үткәрү эшенә хәйриячеләрне тарту максатында «Остров» махсус хәйрия фонды оештырылды. Фондның Попечительәр советы рәисе- легендар совет спортчысы, Россиянең Хоккей федерациясе президенты Владислав Третьяк.

# Торак архитектурасы истәлекләре





**XIX гасырда төзелгән колонна портиклы торак йорт (республика күләмендә әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты)**

Өяз шәһәрләре өчен типовой проект буенча XIX гасырның уртасында төзелгән бу колонналы йорт – ул заманда утраудагы бай агач гражданлык корылмаларының яхшы сакланган бердәнбер өлгесе.

Кайбер мәгълүматлар буенча 1918 елда Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясенең штабы нәкъ менә шушы йортта урнашкан. Утрауда озак яшәгән кешеләр сөйләве буенча, бу йортта, аның элеккеге хуҗаларын куып чыгарып, Республиканың Революцион хәрби советы рәисе Лев Троцкий торган. Хәзерге вакытта инвестор ярдәме белән бу йортта хосусый торагы булган өч гаиләне утрауда төзелгән яңа - барлык уңайлыклары булган йортка күчерү процессы бара. Алар күчеп киткәннән соң бирәдә комплекслы реставрацияләү башланачак. Бу йортта Гражданнар сугышы музее ачу күздә тотыла.

Инвестор:
«Грань» төзелеш компаниясе.
Генераль директоры Л.В.Анисимов.

**Тимофеев – Терентьев – Бровкин – Дьячковлар йорты (республика күләмендә әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты)**

Бу йорт XIX гасыр ахыры торак архитектурасы үрнәге булып тора. Кирпечтән һәм агачтан төзелгән ике катлы йорттан гыйбарәт. Бина өлеше астында подвал каты бар. Аңа капка аркылы, кырый фасад ягыннан кереп була. Йортның бу өлешендә кирпечтән «елочка» рәвешендә түшәлгән идән һәм короб формалы гөмбәз сакланган. Икенче кат такта белән тышланган һәм уелма агач детальләре булган бурадан гыйбарәт. Ул бинаның үзәк өлешендә урнашкан. Әлеге бинада үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә икенче катта я балкон, я бу каттан туры урамга чыгучы аерым ишек булганлыгы ачыкланды. Хәзерге вакытта бинаның көньяк канаты гына сакланган, төньяк канаты тулысынча юкка чыккан. Төньяк өлешендә сакланып калган нигезләрне ачу буенча эшләр башкарылды, нәтиҗәдә бинаның баштагы үлчәмнәре һәм төп диварларның урыны ачыкланды. Бу мәгълүматлар бу истәлекне реставрацияләү һәм яңадан төзү проектыын эшләү өчен нигез булды.

Зөя утравында даими яшәүчеләр сөйләгәннәргә таянып, объектны тикшерүчеләр шуны ачыклады: йорт почетлы сәүдәгәрләр нәселе – Каменевларныкы булган. Ә Тимофеев, Терентьев, Бровкин һәм башка фамилияләр күршеләрнеке яки национализациядән соң төрле елларда монда яшәгән кешеләрнеке булып чыкты.

Тарихи-архив эзләнүләр һәм урында тикшеренүләр буенча бу йортка бәйле тегермән булуы ачыкланды.

2012 елда бу объектта нигезләрне ныгыту һәм гидроизоляцияләү, ярыкларны сылау, диварларны ныгыту, диварларның кирпеч һәм ак таш тезмәләрен реставрацияләү, икенче кат диварларының агач тышлыгын сүтү, бураның аскы өлешләрен алыштыру эшләре башкарылды. 2013 елда тәрәзәләрнең һәм ишекләрнең агач блокларын, уелма бизәкле йозлекләрне һәм кәрнизләрне реставрацияләү эшләре дәвам иттереләчәк, йортның таш элементларын – нигезләрен кору, кирпеч диварларын тезү буенча эшләр бара.

Төзәтү-реставрация һәм торгызу эшләре комплексы проектны гамәлләштерү кысаларында алып барыла.



# Торак йортлар









Зөя утравын торгызу процессы башланганчы биредәге дистәләгән гаиләләр тузган торакта – сусыз, канализациясез, җылыту системасы булмаган йортларда яшәгәннәр, күп еллар капиталь ремонт ясалмау сәбәпле, алар еш кына җимерелеп төшү алдында торганнар. Утрауның үзендә үк күпфатирлы зур булмаган йортлар төзергә карар ителде. Йортлар XX гасырның икенче яртысында юкка чыккан биналар урынында - буш муниципаль җир участокларында төзелде.



Бу исә, беренчедән, Зөя утравының планлы структурасын торгызырга, икенчедән, утрауда яшәүчеләр өчен яшәү һәм эшләү шартлары тудырырга мөмкинлек бирде. Ниһаять, бар уңайлыклары булган торакка күчкән кешеләрнең ни дәрәҗәдә шатлануын күзаллау кыен түгел.

Инвестор:
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды, башкарма директоры Тәлгать Абдуллин.






# Зөя утравында археология тикшеренүләре







Зөя утравы археология мирасының уникаль объекты булып тора, аның тарихи-мәдәни ландшафтының формалашуы борынгы заманнардан ук бервзлексез барган. Халыкның бу районга актив рәвештә күчүенең сәбәбе шунда ки: елгаларның уникаль системасы үзенең биологик ресурслары белән кешеләр игътибарын җәлеп иткән. Утрауга ялганып торган тугайда күпсанлы археология истәлекләре мәгълүм, аларның иң беренчеләре таш гасырга карый.

Утрау территориясен беренче үзләштерү Ананий археология культурасы чоры (безнең эрага кадәр VIII-V гасырлар) белән билгеләнә. Археологик казулар нәтиҗәсендә әлеге археология культурасына бәйле артефактлар табылган. Соңыннан территория яшәү өчен берничә тапкыр җайлаштырыла, моны безнең эрага кадәр I меңьеллыкның беренче яртысына, II меңьеллыкның беренче яртысына караган казу урыннарында табылган әйберләр дәлилләп тора. Әлеге табылдыклар бу җирнең төрле чорларда Зөя елгасы тамагын үзләштерүче кешеләрнең күңеленә ятышлы булганлыгын күрсәтә.

Бу урыннарга актив төстә күченү Урта гасырлар чоры белән бәйле. Елга юллары аша төбәкара һәм халыкара сәүдәнең үсеше елга буйларында авылшәһәрләр барлыкка килүгә этәргеч ясаган. Зөя елгасы тамагы, һичшиксез, Көнчыгышны Көнбатыш белән тоташтыручы трансконтиненталь Идел елгасы юнәлешендәге уңайлы сәүдә пункты буларак үзенә тартып торган. Моны X - XI гасырларда Зөя янында барлыкка килгән болгар авыллары раслап тора. Шул чордан башлап бу территория актив рәвештә болгарлар тарафыннан үзләштерелгән, Зөя шәһәренең үзенең һәм аның посады территориясендә Болгар чоры (XI-XV гасырлар) табылдыклары булу шуны күрсәтә. 1551 елга – кальга төзү вакытына - калкулык һәм аның янындагы территориядә инде болгар-татар һәм Идел буе-фин халыклары яшәгән.



Шәһәрнең алдагы үсеше Зөя тамагын озакка сузылган үзләштерү тарихында чираттагы этап булган. XVI-XVII гасырларда шәһәр бик югары үсешкә ирешкән, бу хәл археология мирасы формалашуның активлыгында да чагылыш тапкан. Посадка күчеп утыруның интенсив барышы уникаль юеш катлам барлыкка килүгә китергән, бу катлам органик әйберләрнең (агач йортлар, хуҗалык корылмалары, күнкүреш предметлары, күн эшләнмәләр, тукыма, эрләгән җеп һ.б.) яхшы саклануын тәэмин иткән. Соңгы елларда җимерелеп баручы яр сызыгында саклау-коткару буенча археология эшләре үткәрү күпсанлы XVI-XVIII гасыр корылмаларын ачарга мөмкинлек бирде. Урамнары һәм йортлары калдыклары буенча урта гасыр шәһәренең планиграфиясенә реконструкция ясап була. Казулар вакытында табылган чын тарихи әйберләр яңартылучы музей-тыюлыкның әһәмиятле экспонатлары була алачаклар. Мәдәни калдыкларны археологияләштерү өчен XIX-XX гасырлар чоры да мөһим этап булып тора.

XIX гасырда - XX гасыр башында Зөя шәһәренең монастырьлары, храмнары, җәмәгать биналары, түшәлгән урамнары булган структурасы формалашкан. Алга таба, дингә каршы көрәш сәясәтен гамәлләштерү нәтиҗәсендә гыйбадәт биналарының күбесе җимерелгән. Шәһәр тормышы үзгәрешенең җитди факторы - Куйбышев сусаклагычы төзелү, нәтиҗәдә посадның шактый өлешен су баскан һәм ул утраугa әйләнеп калган. Барлык бу вакыйгалар шәһәр үсешенең үзгәрешенә һәм алга таба бетүгә йөз тотуына китергән, яңа археология объектлары барлыкка килүнең бер этабы булган.

2010-2012 елларда Татарстан Республикасында Зөя утрау-шәһәрен торгызу максатында кабул ителгән программаны гамәлгә ашыру буенча археология эшләре алып барыла. Бу реставрация ясала, торак йортлар төзелә, төзекләндерелә һәм коммуникацияләр үткәрелә торган урыннарда киң колачлы археология тикшеренүләре үткәрергә мөмкинлек бирде. Гомумән алганда, кыска гына вакыт эчендә утрау территориясендәге мәдәни катламның 20 мең кв м артыграк өлеше өйрәнелде. Бу эшләрдә Мәскәү, Яшел Үзән, Киров, Йошкар-Ола һәм Россиянең башка шәһәрләре белгечләре катнашты.

Утрау территориясендә яңа торак йортлар һәм хуҗалык корылмалары төзелә торган урыннарда үткәрелгән казу эшләре әһәмиятле нәтиҗәләр бирде. Мәсәлән, Иоанн Предтеча монастыреның хуҗалык блогын төзү урынында борынгы бер хуҗалыкның базы һәм хуҗалык чокыры табылды, алар XIX гасыр башында, бу мәйданга Иоанн Предтеча монастыре кергәнче үк булганнар.








# Зөя утравында археология тикшеренүләре










Әлеге районда казылып табылган бер хуҗалык корылмасы һәм аның XVII-XIX гасырлар дәвамында үзгәреше өйрәнелде.

Раштуа, Успение, Мәскәү урамнарын төзекләндерү, аларда торак йортлар төзү барышында археологлар да казу эшләре алып бардылар, XVI гасырның икенче яртысында Зөя территориясен үзләштерүгә бәйле борынгы объектлар өйрәнелде. Еленин урамындагы казу эшләре нәтиҗәләре Зөя территориясен үзләштерү тарихы буенча кызыклы материал бирде, биредә өч гасырга якын чор дәвамында яшәгән йорт-хуҗалык йәм аның корылмалары ачылды.

Тикшеренү барышында Зөя утравы территориясендә Никола Чудотворец (Никольская урамы), София (Троица урамы) чиркәүләре, шулай ук Иоанн Предтеча монастыре (1795 елга кадәр хәзерге Раштуа тыкырыгы тирәсендә) янындагы XVI гасыр ахыры - XVIII гасыр каберлекләре табылды. Успение монастыре тирәсендәге ике туганнар каберлеге XX гасырның беренче чирегенә бәйле, аларның барлыкка килүе Гражданнар сугышының һәм сәяси репрессияләр дәверенең фаҗигале чорларына карый булса кирәк.



Зөя утравын алга таба өйрәнүдә тауның аскы өлешендә, елга вокзалы ягында үткәрелүче тикшеренүләр аерым әһәмияткә ия. Бу территориядә мәдәни катламнарның озак вакытлар формалашуы нәтиҗәсендә көчле катлам, археологиядә – юеш катлам барлыкка килгән. Мондый катламнарның үзенчәлеге органик матдәләр сакланышының югары дәрәҗәсен тәэмин итә. Елга вокзалы урынында, бинасын төзи башлаганчы ук зур казу эшләре алып барылды, археологлар монда 2 метрдан артык тирәнлектә XIX гасыр –XVIII гасыр башы агач корылмаларының горизонтын ачтылар. Борынгырак катламнар әлегә тикшерелмәгән. Казу эшләре барышында табылган бүрәнә кисемнәре XVI-XVIII гасыр Идел буеның Казан өлешенең дендрохронологик шкаласын аныкларга мөмкинлек бирде.

Мәдәни катламнарның барлыкка килү вакыты нумизматика материаллары ярдәмендә яхшы билгеләнде. XIII-XV гасыр болгар-татар чоры әйберләре дә бар, атап әйткәндә, болгар традицияләрендә эшләнгән су сибү савытлары, кызыл балчыктан чүлмәк савыт-саба. Тагын да борынгырак чорга караган табылдыклар да игътибарны җәлеп итә. Күп кенә табылдыклар бу калкулыкны бронза дәверендә һәм борынгы тимер гасырда үзләштерүне тасвирлый.

Тикшеренүләр нәтиҗәсендә ябык комплекслардан (базлардан, аскы катлардан, хуҗалык чокырларыннан) тупланган археология җыелмалары киләчәктә тулаем Урта Идел буеның шәһәр матди культурасы үзгәрешен күзалларга мөмкинлек бирәчәк. Утрау территориясендә, төзү эшләре барган урыннарда археологлар тарафыннан саклау-тикшерү эшләре үткәрү XVI гасырның икенче яртысы -XIX гасырларда, соң урта гасыр һәм өяз шәһәре төзелеше барышы турында яңа мәгълүмат җыярга мөмкинлек бирде. Казу эшләре вакытында борынгы урамнарның юнәлешләре, хуҗалыкларның төзелмәсе ачыкланды.

Күп гасырлар буе яшәп килгән Зөя шәһәренең мәдәни катламында борынгы корылмаларның калдыклары сакланып калган, алар җәмәгать, торак һәм хуҗалык вазыйфалары өчен төзелгән агач һәм таш корылмалардан, төрле хуҗалык чокырларыннан гыйбарәт. Тикшеренүләрне дәвам итү утрауның борынгырак тарихына: XVI гасыр Зөя шәһәреннең кальга ныгытмаларын, урамнарның беренчел планын ачыклауга бәйле мәсьәләләрне күздә тота, объектларның урыннары язма чыганаклар буенча мәгълүм. Тикшеренүләрнең перспективалы юнәлеше – музейлаштыру һәм туристлык маршрутларына кертү максатында чиркәүләрнең совет чорында шартлатылган таш харәбәләрен чистарту.





# Инфраструктура (юллар, мәйданнар, яшелләндерү)









Яңарыш башланганчы Зөя шәһәре, бетүгә йөз тотучы поселокның классик үрнәге иде. Ак таш түшәмәсе сакланып калган берничә урамны исәпкә алмаганда, анда каты өслекле юллар бөтенләй юк иде. Сүүткәргеч система да, канализация дә булмаган, эчә торган су нитратлар күләме буенча нормадан берничә тапкыр артып киткән. Йортлар инде җимерелеп баручы мичләргә ягып җылытылган, утын юнәтү мәсьәләсендә һәрвакыт проблемалар килеп чыккан, аеруча өлкән яшьтәге кешеләр өчен. Утрау өстеннән, баганалар аша башка районнан килүче электр энергиясе гел булып тормый. Коммуникацияләр булдыру барышында утраугa магистраль көнкүреш газы килде, су чистарту системасы булган су алу җайланмасы куелды, канализация станциясе төзелде.



Дамба буйлап электр белән тәэмин итүнең яңа линиясе сузылды, Зөя урамнарын хәзер тарихи стильдәге фонарьлар бизәп тора. Туристлык маршрутлары буйлап бетон юллар түшәлде. Быел утрауны киң колачлап яшелләндерү, йөзләгән агач утырту, урамнарны газоннар һәм чәчәкләр белән бизәү эшләрен дәвам итү күздә тотыла.

Инвесторлар:
«Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.
Генераль директоры Р.А.Кантюков.

«Сетевая компания» ААҖ.
Генераль директоры Д.Х.Сафиуллин.






# Елга вокзалы (2011)










Елга вокзалы Зөя шәһәренең аскы өлешендә төзелде, аның составына касса, көтү залы, «Утрау-шәһәр Свияжск» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее ның туристлык- мәгълүмат үзәге, һәм пассажирлар өчен зур булмаган кафе керә. Елга суднолары белән беррәттән, вокзал турист автобуслары да кабул итәчәк.



Инвестор:
«ПСО «Казань» ҖЧҖ.
Генераль диреторы Р.Х.Җиһаншин.







# Йомгаклау







Болгарда һәм Зөя утравында бер-ике ел элек булган кешеләр бу борынгы шәһәрләрдәге үзгәрешләрнең колачына таң кала. XX гасырның гына түгел, башка чорларның да озак еллары буена Болгарның һәм Зөя утравының истәлекләре ташландык хәлдә,, алар акрынлап җимерелә баралар иде. Белгечләр бәяләве буенча, киң колачлы реставрация тагын берничә дистә ел ясалмаса, бу объектларның күбесе юкка чыгар иде. Татарстанның Беренче Президенты М.Ш.Шәймиев тәкъдиме нәтиҗәсендә борынгы Болгарны һәм утрау-шәһәр Зөяне яңарту эше башлану мәдәни мирасыбызны архитектура ядкәрләре рәвешендә саклап калырга гына түгел, аларга Ватаныбызны үстерүгә хезмәт итүче яңа икътисади мөмкинлекләр бирергә дә ярдәм итте.

Иң әһәмиятлесе шунда ки, «Яңарыш» фонды оештырылу моңа битараф булмаган кешеләргә шушы игелекле эштә катнашу мөмкинлеге бирде. Тарихи һәм мәдәни мирасны торгызу Татарстанда гомумхалык эшенә әйләнде. Әлеге киң колачлы проектны гамәлгә ашыруда җәмгыятьнең барлык катлам вәкилләре катнаша.

«Яңарыш» республика фондына һөнәрләре, матди мөмкинлекләре төрле булган кешеләр, төрле милек формалы, эшчәнлекләренең уңышлыгы төрле дәрҗәдә булган предприятиеләр һәм оешмалар ярдәм итә.





Фонд эшен студентлар һәм укучы яшьләр, спортчылар һәм иҗади зыялылар хуплый.

Проектны гамәлләштерүдә татарстанлылар гаиләләре белән, ә кайвакыт бөтен авыллары белән катнаша. Һич арттырмый әйтеп була: «Яңарыш» фондына бөтен Татарстан булыша.

Фондның Попечительләр Советы барлык хәйриячеләрнең исемнәрен махсус истәлек китапта - «Яңарыш» республика фондының Хәйриячеләр китабында мәңгеләштерергә карар итте. Китапның инде өч томы басылды.

Шушы өч томга 22 мең хәйрияче исеме керде (I томда – 5 меңнән артык, II томда – 10 меңнән артык, III томда – 7 меңнән артык исем). Шунысы куанычлы, күп кенә хәйриячеләрнең исеме ике томга, хәтта барлык өч томга да кертелде.

Проектта катнашучыларның һәрберсе шушы олы вакыйгага шәхсән катнашуы белән, 2011-2012 елларда гомумхалык байлыгы булган Зөя утрау–шәһәрендә - 14, Болгарда 10 объектның сафка басуы белән горурлана ала. Бу шәһәрләрнең күренешен үзгәрткәндә без үзебез дә яхшыга үзгәрәбез, рухияткә ирешәбез. Мөгаен, бу торгызылган тарихи истәлекләргә караганда да мөһимрәк һәм кадерлерәктер, чөнки без үзебез дә, җәмгыятебез дә яңарыш кичерә.









# «ЯҢАРЫШ» Фонды

**БАНК РЕКВИЗИТЛАРЫ:**
**«Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы**

ИНН 1655069125 КПП 165501001

Расчетный счет 40703810600000000153
в ЗАО «Татсоцбанк» г. Казань
БИК 049205703
КОР/СЧЕТ 30101810500000000703
или
Расчетный счет 40603810200020000245
в ОАО АК БАРС БАНКЕ г. Казань
БИК 049205805
КОР/СЧЕТ 30101810000000000805

Назначение платежа:
добровольный благотворительный взнос
(НДС не облагается.)

Tatsotsbank, ul. Tschernitschewskogo 18/23
420111 Kazan, Russian Federation
Corr.Bank: COMMERZBANK AG, Frankfurt/Main, Germany
(SWIFT code: COBA DE FF)
Bank Beneficiary: №400 8866790 00 USD
Tatsotsbank, Kazan, Russia
Beneficiary Account: № 40703840100000000005
Fond Vozrozhdeniya

Bank Beneficiary: №400 8866790 01 EUR
Tatsotsbank, Kazan, Russia
Beneficiary Account: № 40703978800000000002
Fond Vozrozhdeniya

**АДРЕСЫ: 420014 Казан шәһәре,**
**Кремль, 1 нче подъезд**
**Тел.: (843)567-87-07, факс (843)292-32-02**

*Барлык эшләр дә «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасының турыдан-туры җитәкчелегендә башкарыла.*

*Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды Попечительләр Советы Рәисе,*
*Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев.*

*Башкарма Директоры,*
*Татарстан Республикасы Президентының социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе Т.П.Ларионова.*

Макетның дизайны: С.И.Смолкин, Е.В.Груздев.
Фоторәсемнәр: Н.Г.Исмәгыйлов, В.В.Касырин, М.Б.Козловский, Р.З.Мәхмүтов, Г.Г.Садыйков, В.В.Четверкин, В.В.Чумаков, Ф.В.Чумаков.

**РЕДАКЦИЯ ТӨРКЕМЕ:**
Т.П.Ларионова
Р.Р.Хәйретдинов
А.Н.Силкин
А.Г.Ситдыйков
Ю.А.Егорушкин
И.Р.Кузьмина
Р.Р.Вәлиева

**«Главдизайн» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте**
Ф.В.Чумаков, директор
Н.Н.Шәйдуллина тәрҗемәсе
© ООО «Главдизайн», 2013